ЧӘРШӘМБЕ
27 МАРТ
1940 ел
№ 71 (5871)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—23, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

Җир органнары эшенә зур сынау

Социалистик авыл хуҗалыгындагы эшләр гаять дәрәҗәдә катлаулы. Әгәр дә элеккеге авыл эш кораллары итеп сабан белән сукадан башка нәрсәне белмәгән һәм күрмәгән булса, хәзер колхозлар тракторлар, комбайннар, автомашиналар һәм башка бик күп төрле машиналар белән коралландылар. Соңгы ун елда совет авылының йөзе бөтенләй үзгәрде.

Колхозларның кырчылык тармагы гына түгел, бәлки терлекчелек, яшелчә-бакчачылык тармаклары да зур һәм катлаулы хуҗалык булып әверелделәр, алар да бөтенләй яңа баштан корылдылар.

Колхозлар хәзер бөртекле культураларны күпме мәйданга һәм нинди сортлар белән чәчүне планлаштыру кебек кырчылыкның аеруча җаваплы эшләрен үзләре хәл итәләр. Социалистик эре хуҗалыкны үстерү, ныгыту, идарә итү буенча колхозларда гаять бай тәҗрибәләр тупланды, гүзәл кадрлар, югары иген уңышының мастерлары тәрбияләнеп үстеләр. Колхоз строе җиңде, колхоз төзелешенең киләчәге гаҗәеп зур, аның тагын да чәчәк атуы өчен бөтен шартлар тудырылды.

Колхоз төзелеше эшләренең әнә шулай катлаулануы хәзер авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүне тамырыннан яхшырту бурычын бөтен кискенлеге белән куйды. Бу, иң элек, җир органнарына кагыла. ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының җир органнары структурасы турындагы үткән ел декабрь аенда кабул иткән карары, җир органнарын авыл хуҗалыгының сугышчан штабы итүне, алар эшен яңа баштан коруны, эш методларын бөтенләй үзгәртүне күз алдында тота.

Ләкин колхозлар белән турыдан-туры җитәкчелек итәргә, иген уңышын күтәрү һәм терлекчелекне үстерү өчен колхозлар белән бер рәттән җавап бирергә тиешле җир органнары әле үз эшләренә сизелерлек үзгәреш кертмәгәннәре юк. Моны без Татарстанда язгы чәчүгә хәзерлектә дә күрәбез. Моны әле генә үткән партия конференцияләре дә бик ачык күрсәттеләр. Район җир бүлекләренең һәм Татнаркомземның эше партия конференцияләрендә каты тәнкыйть ителү һич тә очраклы хәл түгел, чөнки җир органнары начар эшлиләр әле.

ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе Татнаркомземның җир органнарына җитәкчелек итүдә канцелярияча-бюрократлык методны шушы вакытка кадәр бетермәгәнлеген, авыл хуҗалыгында эшнең торышына кирәкле анализ алып бармавын, җитәкчелек итү эшен еш кына сукыр килеш, эшне һәм колхоз производствосының торышын белмичә алып баруын, артка калып баручы районнарга, МТС ларга һәм колхозларга вактында ярдәм күрсәтмәгәнлеген әйтеп үтте.

Бу бәя район җир бүлекләренә дә бик туры килә. Район җир бүлекләренең дә күбесендә нак әнә шундый яраксыз практика, әнә шундый эш стиле хөкем сөрә. Район җир бүлекләренең төп белгечләреннән агрономнар, зоотехниклар, ветврачлар, инструкторлар иҗад эше белән чолганып алу, һәрбер яңалыкны эләктереп ала белү, колхоз производствосына турыдан-туры җитәкчелек итү, күбрәк вакытны авылларда, колхозчылар арасында үткәрү урнына, күбрәк кәгаз дәрьясына чумалар, канцелярия пленлегеннән котыла алмыйлар. Белгечләр башын сводкалар төзетү, статистика саннарын җыйдыру, алар өстендә чокчынып утыру белән әйләндерәләр. Күптән түгел Әгерҗе һәм Чепья район җир бүлекләре эше белән танышу һәм алар турында басылып чыккан материаллар әнә шуны күрсәттеләр. Кызганычка каршы, мондый хәл бу ике район өчен генә характерлы түгел. Белгечләр күп кенә район җир бүлекләрендә канцелярияче хезмәткәрләргә әйләнгәннәр.

Район җир бүлекләренең, авыл хуҗалыгы белгечләренең производстводан болай аерылулары колхоз төзелеше эшенә җитәкчелек итүгә бик нык зарар китерә. Кайсы колхозның ничек эшләве күздән югала башлый, өзеклекләр килеп чыга. Шуннан соң инде райкомнар һәм райбашкармалар җир бүлекләре эшен үзләре башкара башлыйлар, вәкилләр җибәрү кампаниясе башлана, өзеклекне „штурм“ белән алу өчен шау-шу куба башлый.

Партиянең район комитетлары һәм район советларының башкарма комитетлары исә җир органнары эшләргә тиешле эшләрне үзләре үтәмәскә, Азнакай районындагы шикелле МТС лар эше турында райзо работникларыннан отчет ясатып, МТС работникларын читтә калдырмаска, бәлки җир бүлекләре эшенә җитәкчелек итәргә, алардан партия һәм Совет хөкүмәте карарларын үтәүне таләп итәргә, шуның өчен җаваплылык тойгысын көчәйтергә, кадрлар сайлап алуда, аларны тәрбияләүдә, чын мәгнәсе белән дәүләт эшлеклеләре итүдә ярдәм күрсәтергә тиешләр. Бурыч — әнә шуннан гыйбарәт.

Ә район җир бүлекләрен яңа структура буенча каралган кадрлар белән тәэмин итү кебек мөһим чараны үтәүдә Татнаркомзем да, район оешмалары да әле бик аз эшләделәр. Мисаль өчен ике генә район җир бүлеген алыйк.

Мөслим район җир бүлегендә бүгенгә көнне бер бухгалтер, 2 инструктор - бухгалтер, 2 агроном һәм бер ветврач җитми. Питрәчтә 5 зоотехник, 2 агроном, 3 ветврач һәм 2 җир төзүче юк. Тат. Ходяш МТС ы баш агрономсыз эшли. Район җир бүлеге мөдире иптәш Белов „Питрәчтә бер баш агрономнан башка бер белгеч тә юк“ ди. Хәл, чынлап та аяныч. Район җир бүлекләренең штат расписаниесен Татарстан шартларына карата эшләүне, раслауны һәм урыннарга җиткерүне Татнаркомзем белән Татнаркомфин бик соңга калып җибәрделәр.

Без язгы чәчү алдында торабыз. Партия һәм Советлар хөкүмәте җир органнарыннан эшне яңа баштан коруны формаль яктан түгел, бәлки эчтәлек ягыннан яңартуны, авыл хуҗалыгының сугышчан штабына әверелүне таләп итәләр. Җир органнарының яңача эшләүләре чәчүгә хәзерлектә һәм чәчүне большевикларча үткәрүдә бөтен тулылыгы белән күренергә тиеш. Чәчү, алар өчен зур сынау булачак. Җир органнары работниклары чәчүне яхшы үткәреп, югары иген уңышы өчен көрәштә авыл хуҗалыгының сугышчан отряды булуларын эштә күрсәтергә тиешләр.

ВЦСПС ТА

ЭШЧЕЛӘРНЕҢ ИНДИВИДУАЛЬ ТҮТӘЛ БАКЧАЛАРЫН ҮСТЕРҮ

Йөз меңнәрчә эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең индивидуаль түтәл бакчалары бар. ВЦСПС секретариаты барлык профсоюз оешмаларын, бигрәк тә фабзавкомнарны һәм месткомнарны эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә түтәл бакчалыгы хуҗалыгы оештыруда иң күп булышлык күрсәтергә мәҗбүр итте.

Индивидуаль түтәл бакчасы ясарга теләүчеләргә фабзавкомнар һәм месткомнар аларга җир участкылары беркетүдә, кирәкле инвентарь һәм орлык табуда ярдәм итәргә тиешләр. Язгы чәчү кампаниясенә хәзерлек буенча бөтен эш 10 нчы апрельдән соңга калмыйча тәмам булырга тиеш. Индивидуаль түтәл бакчалары оештыру, яшелчәдән һәм бәрәңгедән югары уңыш алу өчен көрәш мәсьәләләре буенча клубларда һәм кызыл почмакларда консультацияләр оештырырга кирәк.

ВЦСПС секретариаты фабрика-завод комитетлары янында түтәл бакчалары советлары һәм өчлекләр төзүне кирәксез дип тапты. Индивидуаль түтәл бакчалары мәсьәләләре белән профсоюз органнарының торак-көнкүреш комиссияләре һәм аларның активы шөгыльләнергә тиеш.

(ТАСС).

20 нче мартта Ленинград шәһәренең хезмәт ияләре Карелия бугазында батырларча сугышкан данлыклы сугышчы-чаңгычыларны каршы алдылар.
РӘСЕМДӘ: сугышчы-чаңгычылар Ленинградта.
М. П. Янов фотосы (ТАСС фото-клишесы).

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендәге сайлау округларыннан СССР Верховный Советына сайлаулар турында беренче саннар

СССР Верховный Советына сайлаулар буенча округ күләмендәге сайлау комиссияләренең СССР Верховный Советы Президиумы секретариатына алынган мәгълүматларга караганда, 1940 нчы елның 24 нче мартында Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә Союз Советына сайлаулар буенча 43 сайлау округының барсында да һәм Милләтләр Советына сайлаулар буенча 12 сайлау округының барсында да сайлаулар булган.

Украинаның һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендәге барлык шәһәрләрдә, авылларда һәм поселокларда сайлаулар 24 нче мартта иртән 6 сәгатьтә башланган һәм һәр җирдә дә кичке 4—5 сәгатькә сайлаучыларның зур күпчелеге тавыш биреп бетергән. 24 нче мартта төнге 12 сәгатькә тавыш бирү тәмам булган.

Округ комиссияләренең беренче саннарына караганда, Украина ССР ның көнбатыш өлкәләрендәге сайлау округларында сайлауларда сайлаучыларның гомуми санының 96 һәм аннан да артыграк проценты катнашкан.

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләре округларында СССР Верховный Советына депутатлар итеп коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары сайланганнар.

КОЛХОЗ ҺӘМ СОВХОЗ БАСУЛАРЫНДА КАР СУЛАРЫН ТОТУ ЭШЕН ОЕШТЫРУ ТУРЫНДА

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы карары

Кар суларын тоту эшенең уңышны күтәрүдә иң әһәмиятле агротехника чараларының берсе булуын искә алып ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы карар бирә:

1. Колхоз һәм совхоз басуларында кар суларын тоту эшен оештыру буенча ВЛКСМ Өлкә Комитетының һәм алдынгы колхозларның инициативасын яхшы дип табарга.

2. Татарстан Наркомземына, район һәм МТС директорларына, район башкарма комитетларына һәм ВКП(б) ның район комитетларына,—һәрбер колхозда һәм совхозда кар суларын тоту эшен җәелдерүне тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә. Һәрбер бригадага һәм звенога кар суларын тотыларга тиешле участкыларны һәм мәйданнарны күрсәтеп нык билгеләргә.

3. ВЛКСМ Өлкә Комитеты аның тарафыннан шушы елның 25 нче мартында кабул ителгән карарның ВЛКСМ райкомнары һәм комсомолның башлангыч оешмалары тарафыннан үтәлешенә көндәлек контроль ясарга, бу эшкә союздан тыш яшьләрне киң күләмдә тартырга мәҗбүр итәргә.

4. Өлкә һәм район газеталары редакторларына кар сулары тоту эшенең барышын газетада киң яктыртырга тәкъдим итәргә.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре
Е. МАТВЕЕВ.

26 март, 1940 ел,

КАР СУЛАРЫН ТОТУ ЭШЕНДӘ КОМСОМОЛЕЦЛАРНЫҢ КАТНАШУЫ ТУРЫНДА

ВЛКСМ НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ БЮРОСЫНЫҢ 1940 НЧЫ ЕЛ 25 НЧЕ МАРТ КАРАРЫ

Һава шартлары нинди генә булса да югары иген уңышы алу өчен кар суларын тотуның гаять зур әһәмияте барлыгын искә алып, ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты бюросы карар бирә:

1. ВЛКСМ райкомнарын һәм комсомолның колхозлардагы, совхозлардагы башлангыч оешмаларын яшьләр арасында киң күләмдә массовый-аңлату эше җәелдерергә, колхозчыларны һәм совхоз эшчеләрен басуларда кар суларын тоту эшенә тупларга мәҗбүр итәргә.

2. ВЛКСМ райкомнарына,—кар суларын тоту эшендә колхозлардагы һәм совхозлардагы комсомолецларның алда баруларына ирешергә. Сталинград өлкәсе комсомолецларыннан үрнәк алып, кар суларын тоту өчен махсус көннәр үткәрергә.

1940 нчы елның 29 нчы мартында республикадагы комсомолецларның һәм яшьләрнең массовый күләмдә кар сулары тотарга чыгуларын оештырырга.

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре
А. ПЕРОВ.

ХУТОРЛАРДАН—КОЛХОЗ ҮЗӘКЛӘРЕНӘ

СССР ның авыл хуҗалыгы банкысы 1940 нчы елга хуторлардан колхоз үзәкләренә күчү өчен колхозчыларга кредитлар ачты. Үткән елны хуторлардан колхоз үзәкләренә 300 меңнән артык колхоз хуҗалыгы күчкән иде. Яңа урында йорт салуга һәм хуҗалык коруга кредитлар бирү төсендә дәүләт аларның күбесенә зур ярдәм күрсәтте.

Быел авыл хуҗалыгы банкысы хуторлардан колхозчылар күчү сәбәпле шактый зурая торган колхоз үзәкләрен төзекләндерүгә колхоз идарәләренә дә кредитлар бирә. Кредитлар коелар казуга, җәмагать мунчалары салдыруга, юлларны яхшыртуга, агачлар утыртуга, клублар, балалар ясле-ләре һәм башка төрле хуҗалык корылмалары төзүгә бирелә.

(ТАСС),

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ КУӘТЕ ТУРЫНДА АМЕРИКА МАТБУГАТЫ

НЬЮ-ЙОРК, 22 март. (ТАСС). Кызыл Армия турында күп атналар буена ялган хәбәрләр биреп һәм ак финнәрнең уйлап чыгарылган „җиңүләре“н язып килгән буржуаз хәбәрчеләр хәзер киресен язарга мәҗбүр булалар. Матбугатның төшкән дәрәҗәсен яңадан аякка бастыру өчен күп кенә хәбәрчеләр хәзер үзләренең „ялгышларын“ оялмыйча икрар итәләр һәм төрлечә акланырга маташалар.

Мәсәлән, „Нью-Йорк пост“ газетасының хәбәрчесе, Америка хәбәрчеләренең Кызыл Армиянең көчен һәм куәтен белә алмаганлыкларын белдергән, чөнки ак финнәр аларга фронтта булырга рөхсәт бирмәгәннәр. Фронтта буласы урында хәбәрчеләр көннәр буе Хельсинкида кафеда үткәргәннәр һәм „информацияләр“не Маннергейм агентларыннан алганнар. Хәбәрчеләр үз ялганнарының корбаннары булганлыкларын сизгәннәр. „Чикаго дейли ньюс“ газетасының хәбәрчесе Стоу үзенең тәүбә итеп язган мәкаләсендә „күп кенә еллар буена русларның транспорт системасы бик таркау хәлдә дип язып киләләр иде“ ди. Шунлыктан хәбәрчеләр Финляндиядәге хәрби атташеларның Карелия бугазында Кызыл Армия һөҗүмне дәвам иттерә алмаячак, чөнки рәхимсез кыш шартларында армияне тәэмин итү хәл ителә алмаслык мәсьәлә дип белдерүләренә ышанганнар. Стоу болай дип яза:

„Февраль урталарында чит илләрнең хәрби экспертлары Кызыл Армия үзенең һөҗүмен 10 көннән артык дәвам иттерә алмас диделәр, шуңа да карамастан барлык фронтларда кызыл дивизияләр һөҗүмне өзлексез дәвам иттерделәр“.

„Чит ил хәрби экспертлары“ның ышандыруларына һәм Маннергеймның көн саен булып тора торган „җиңүләре“ турында хәбәрчеләрнең язуларына да карамастан, „Нью-Йорк пост“ газетасының хәбәрчесе болай дип икрар итә: „Бу сугыш Кызыл Армиянең сугышка сәләтлелеген һәм батырлыгын күрсәтте. Чит ил хәрби экспертлары һәм дипломатлары Финляндия конфликтының (әһәмиятле сабагын икрар итәл һәм бу хәл көнбатышта сугыш чы илләрнең политикасына, ш лай ук Европадагы вакыйгалә нең киләчәктәге үсешенә дә й гынты ясый“.

„Нью-Йорк геральд трибю газетасының хәбәрчесе Керр, сов авиациясен тыныч халыкка һөҗ итүдә гаепләп, чит ил хәбәрч ләре оятсыз рәвештә ялганлад лар дип икрар итә. Керр, Совет Финляндия конфликтының бөт дәвамында совет авиациясе тын халыкка каршы бер вакытта һава сугышы алып бармады ди белдерә:

Американың „Таймс“ журнал ак финнәрнең җиңүе турында ә һаман да үз хәбәрләренең йогы тысы астында булган чит хәбәрчеләренең солых төзелү т рындагы хәбәрне ишеткәч гаҗә ләнгәнлекләрен белдерә.

„Ньюс уик“ журналы бер-берс нә капма-каршы булган белдер ләр урнаштыра. Маннергеймны „җиңелмәгәнлеге“ турында язу дәвам иттереп, журнал шул вакытта Кызыл Армиянең үзен барлык турыдан-туры сугы бурычларын үтәгәнлеген—Лени градка, Фин заливына һәм Му манск тимер юлына куркыны сызлыкны тәэмин иткәнлеген бе дерә. Аннары журналның язуы ча Финляндиядә сугышны дәва иттерү белән мораль яктан шулай ук стратегия ягыннан кызыксынган Англия—Франц империалистларына Кызыл Арм җиңүләре зур удар ясаган. Шу лыктан үткән атна Англия һ Франция өчен күп кенә караң көннәр китерде һәм ул аларн планнарының җимерелүе диг сүз иде. „Ньюс уик“ Кызыл А мия уңышларының бөтен дөнь да, бигрәк тә кечкенә нейтра илләр арасында Франция дипл матиясенең йогынтысын йомшар канлыгын яза.

Буржуаз хәбәрчеләрнең Фи ляндиядәге вакыйгаләрне боз күрсәтүләре киң катлау укучыл арасында капиталистик матбуга ка ышанычны тагын да йо шартты.

КАРЕЛИЯ БУГАЗЫНДА КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӨҖҮМЕ ТУРЫНДА ШВЕЦИЯ ГАЗЕТАСЫ

СТОКҺОЛЬМ, 24 март. (ТАСС). „Стокһольмс экстрабладет“ газетасының Хельсинкидагы хәбәрчесе Кызыл Армиянең Финляндиядәге операцияләре турында бик мактап яза. Ул болай ди: „Финнәр Фин заливының көнчыгыш ярын руслар кулында калдырып киткәч, руслар электән үк нык уйланган һөҗүмне башладылар. Бу һөҗүм сугышның нәтиҗәсен бер удар белән хәл итте. Руслар бу участкыга артиллериядән җимергеч ут ачтылар. Фин гаскәрләре үз позицияләреннән чигенделәр. Гаять тиз чигенгәндә Маннергейм линиясе артында булган ныгытмалардан файдалану мөмкинлеге искә төшмәгән булса кирәк, Маннергейм линиясендә өзеклек һәлакәтле төстә тирән булып әверелде. Карелия бугазының бөтен көнбатыш ягында чигенү башланды һәм руслар Выборг заливы яры буена килеп җиттеләр. Алар боз өстеннән киск һөҗүм ясадылар. Финляндиян көньяк яры буена 180 километ дан артыкка сузылган яңа фрон ка русларның моторлаштыры ган 3 үрнәк дивизиясе чыкты.“

Аннары хәбәрче фин гаскәр ренең куәтле дошманның һөҗүм нә каршы тора алмаганлыклары гаять куркынычлы хәл туганлык һәм шунлыктан Финляндиян солых турындагы мәсьәләне куя га мәҗбүр булганлыгын яза.

Соңыннан хәбәрче болай „Сугышның соңгы атнасын бәрелешләр гаять каты булд Фин армиясенең көн саен 2 ме ләп кешесе үтерелә һәм ярала иде. Шушы көннәрнең берсен ике полк тар-мар ителгән д сөйлиләр. Русларның артиллер уты коточкыч иде. Артиллер финнәрнең оборона линиясен чы магнәсе белән көлгә әйләндерде

ФИН АРМИЯСЕНЕҢ ЮГАЛТУЛАРЫ ТУРЫНДА „НЬЮ-ЙОРК ГЕРАЛЬД ТРИБЮН“

НЬЮ-ЙОРК, 22 март. (ТАСС). „Нью-Йорк геральд трибюн“ газетасының әле күптән түгел генә Хельсинкидан кайткан Стокһольм хәбәрчесе Керр, финнәрнең югалтулары 15 мең кеше дип хәбәр итүе белән Маннергейм ялганлады дип яза. Чынлыкта финнәрнең 30 меңнән 40 меңгә кадәр кешесе үтерелгән һәм 40 меңнән 50 меңгә кадәр кешесе яраланган.

Кызыл Армия Карелия бугазында һөҗүм иткән вакытта финнәр аеруча зур югалтуларга дучар ителгәннәр. Финнәрнең югары дәрәҗәле бер офицеры Керрга Кеми елгасындагы сугышлар вактында фин гаскәрләренең югалтулары Кызыл Армиянең югалтуларына караганда шактый артыграк булганлыкны белдергән. Фи нәр командованиесе ике зур я гыш ясаган. Ул, Кызыл Арм февральдә һөҗүм башлый алма чак һәм аны озак вакыт ал бара алмаячак дип уйлаган.

Январь урталарында Манне гейм Англиягә һәм Франция Кызыл Армиянең һөҗүмен яз кадәр тоткарлап тора алмаячагы белдергән. Финнәр Фин залив буен саклауга хәзерләнмәгән бу ганнар. Кызыл Армия ныгыты маган пунктларга, шул исәпт Хельсинкидан бары берничә м генә ераклыктагы атауларга ата ясаган. Аннары Керрның язуы караганда, арудан һәм зур юга тулар ясаудан 3 яки 4 ат эчендә фин армиясенең тарал чагын Финляндия хөкүмәте белгә

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Партиянең Бауман район активы жыелышы

Партия оешмаларында отчет-сайлаулар тәмам булды. Хәзер Бауман район оешмаларында актив жыелышлары үткәрелә. Бу жыелышларда коммунистлар ВКП(б) ның район, шәһәр һәм өлкә конференцияләре йомгакларын тикшерә, конференцияләрдә кабул ителгән карарларны үтәү өчен конкрет чаралар билгелиләр. Шушы көн тәртибе белән, 25 нче мартта, партиянең Бауман район активы жыелышы булды. Жыелышка районның житәкче работникларыннан, башлангыч партоешма секретарьларыннан һәм активтан барлыгы 364 коммунист катнашты.

ВКП(б) ның район, шәһәр һәм өлкә конференцияләре йомгаклары турында районком секретаре иптәш Мәлькин доклад ясады. Коммунистлар докладны зур игътибар белән тыңладылар. Докладны, отчет конференцияләрдә тикшерелгән мәсьәләләрне, аларда кабул ителгән карарларны үтәү өчен район партия оешмасы алдында торган бурычларны күрсәтте.

Доклдтан соң фикер алышулар булды. Чыгып сөйләүче иптәшләр ВКП(б) ның район, шәһәр һәм өлкә конференцияләре карарларын бердәм рәвештә яхшы дип табып, аларны үтәү өчен бөтен көчләрен куеп көрәшәчәкләрен белдерделәр. Шул ук вакытта алар аерым саннар һәм фактлар белән докладны тулыландырдылар.

Актив жыелышы, конференция карарларын бердәм рәвештә яхшы дип табарга һәм бу карарларны үтәү көрәшкә барлык коммунистларны, барлык хезмәт ияләрен тупларга, дигән резолюция кабул итте. Резолюциядә, ВКП(б) ның район, шәһәр һәм өлкә конференцияләре йомгаклары турында башлангыч партоешмаларда гомуми жыелышлар үткәрергә һәм конференция карарларын үтәү буенча жыелышларда практик чаралар билгеләргә кирәклеге күрсәтелде.

М.

ӘГЕРЖЕ РАЙОНЫНДА

Әгерждә партиянең район активы жыелышы үткәрелде. Партиянең өлкә конференциясе йомгаклары һәм аны үтәү чарасын үткәрү буенча район партоешмасы алдында торган бурычлар турында ВКП(б) райкомы секретаре иптәш ... доклад ясады.

Жыелышта чыгып сөйләүчеләр партиянең өлкә конференциясе карарлары тулысы белән яхшы дип таптылар, һәм район житәкчеләренең кимчелекләрен күрсәттеләр. Иптәш Мөхәммәтжанов үзенең чыгышында болай диде:

— Безнең район жир бүлеге канәгатьләнерлек эшләми. Аның житәкчеләре колхозларда булмыйлар. Агрономнарның колхозларга булышлыгы йомшак.

Иптәш Хәсинуллин авыл хужалыгы артеле уставын бозу фактларына тукталды. „Кызыл тау" колхозында 8 хужалык колхоздан чыгарылган, шулар арасында кызыл армеец семьяләреннән 2 хужалык бар.

Жыелыш өлкә конференция карарларын тормышка ашыру буенча практик чаралар билгеләде.

КУКМАРА РАЙОНЫНДА

20 нче мартта Кукмара районының партия активы жыелышы булды. Жыелышта 120 кеше катнашты. Партиянең XXI нче өлкә конференциясе йомгаклары турында ВКП(б) райкомы секретаре иптәш ...ельдеев доклад ясады.

Фикер алышуларда катнашучылар Нигматуллин районда язгы чәчүгә хәзерлекнең канәгатьләнерлек булмавын күрсәтте. Сортлы орлыкларны алмашу эше әле тәгәлләнмәгән, чүчүлек материалларын 30 процентка якыны колхозларга житкерелмәгән. Тирес чыгару планы бары 60 процентка үтәлгән. Район жир бүлеге колхозларга начар житәкчелек итә.

Иптәш Вәлиев, Янил МТС ында агитация-масса эшенең йомшак булуы турында сөйләде. Монда газетасы тәртипле рәвештә укылмый. МТС эшчеләре арасында кычкырып укулар һәм беседалар үткәрелми. Трактор бригадаларына өченче культура вагоннары жиһазландырылмаган.

Иптәш Карпов Кукмара МТС ында тракторларга ремонтның сыйфаты начар булуын күрсәтте. Ремонттан чыккан тракторларның магнетолары, свечалары юк. Трактор бригадаларына заправка инвентаре белән тулы тәэмин ителмәгәннәр.

Партия активы жыелышы, партиянең XXI нче өлкә конференциясе карарларын тулысы белән яхшы дип тапты һәм аларны тормышка ашыру өчен конкрет чаралар билгеләде. Жыелыш, язгы чәчүгә хәзерлек һәм аны үткәрү эшендә колхозларга практик ярдәм күрсәтү өчен, партия активыннан 85 кешене колхозларга жибәрергә карар бирде.

(ТатТАСС).

Колхоз комсомол оешмаларына житәкчелекне көчәйтик

Норлат районында 32 колхозда башлангыч партоешмалар юк, ләкин, аларның барында да комсомол оешмалары бар. Комсомол оешмаларының күпчелеге колхозларның хужалык эшләрен яхшыртуда мәсьәләләрендә зур инициатива күрсәтә. Мисалга „Ярыш" колхозы янындагы комсомол оешмасын алырга мөмкин. Бу оешма үзенең жыелышларында колхоз председателенең, бригадирларның, звеноводларның информацияләрен системалы рәвештә тыңлый, хужалык эшләрендәге төп житешсезлекләрне бетерү чараларын күрсәтә, правлениегә практик ярдәм оештыра. Комсомол оешмасы колхозда масса-политик эшне жәелдерүгә зур игътибар бирә. Социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтенә житәкчелек итә.

Комсомол оешмасының инициативасы буенча колхозда йөзләтчылар хәрәкәте башланды. Бу эштә комсомолецлар һәм комсомолкалар үрнәк күрсәтәләр. Комсомолка Гыйфранова һәм Алимева эштәге звеноларга беркетелгән участокларда һәрбер гектардан 35 ар центнер бодай уңышы алырга ирешү буенча йөкләмә алдылар.

Ләкин, колхоз хужалыгына игътибар бирмәүче комсомол оешмалары да бар әле. Мисаль өчен Нариман исемендәге колхоз янындагы комсомол оешмасын алырга була. Бу оешмада 11 комсомолец исәпләнә, аларның күпчелеге колхоз производствосында житәкче эшләрдә эшли. Ләкин комсомол оешмасы аларга эштә бер төрле дә ярдәм күрсәтми. Колхозда масса-аңлату эшләре тиешенчә алып барылмый. Социалистик ярыш, стахановчылык хәрәкәтенә житәкчелек начар. Колхоз политик-хужалык бурычларын үтәүдә артта бара.

Партоешмалар булмаган урыннардагы комсомол оешмаларына районкомның житәкчелеге житәрлек түгел әле. Масса-политик эшне киң жәелдерүдә, партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан колхозлар алдында куелган политик һәм хужалык бурычларны үтәүгә комсомол оешмаларына системалы рәвештә житәкчелек итүне районком игътибар үзәгенә куярга тиеш.

Х. Хәлилев.
М. Гыйсматуллин.

Комсомолның район оешмасы үсә

Комсомолның Яңа Чишмә районы оешмасы 1939 нчы елны һәм 1940 нчы елның беренче кварталында үз сафларына 575 членны кабул итте. 5 яңа башлангыч оешма төзелде.

Шушы вакыт эчендә Яңа Чишмә авылындагы урта мәктәптә комсомол оешмасы 87 кешегә, „Октябрь" совхозында комсомол оешмасы 19 кешегә үсте. (ТатТАСС).

Камиль Якуб исемендәге китап фабрикасының басу цехында накладчик булып эшләүче алдынгы стахановчы иптәш М. Васикова. Ул нормасын системалы рәвештә арттырып үтәү белән бергә, катлаулы басу машинасында мастер булып эшләргә өйрәнә. РӘСЕМДӘ: Иптәш Васикова машинада басылып чыккан продукциянең сыйфатын тикшерә. М. Солтанов фотосы.

Лозовский исемендәге социалистик шәһәрчек турында

Лозовский исемендәге социалистик шәһәрчектә мехкомбинатның дүртәр этажлы 7 торак корпусы бар. Соңгы вакытларда комбинатның коммуналь торак йортлары идарәсе шәһәрчекне төзекләндерү һәм торакларга ремонт ясау өлкәсендә шактый уңышларга ирешә. Шәһәрчекнең беренче һәм 11 нче корпусларына, 5 нче корпусның беренче сексиясенә капиталь ремонт үткәрелде. 9 нчы корпуска электр яктысы бирелде.

Төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча да зур гына эшләр башкарылды. Шәһәрчекнең тирә ягы, андагы бакчалар такта коймалар белән әйләндереп алынды. Бу эшләргә 507 мең сум акча тотылды.

Ләкин шәһәрчектә кимчелекләр бетерелде дип булмый әле. Коммуналь торак йортлар идарәсе работниклары, шулай ук комбинат директоры иптәш Барышников шәһәрчеккә ремонт ясауга һәм бу эшкә тотыла торган сумаларны урынлы файдалануга тиешенчә игтибар бирмиләр. Беренче корпуста үткәрелгән ремонтның сыйфаты начар. Бу корпуска капиталь ремонт үткәрү өчен бирелгән акчаның тотылып бетүенә карамастан, барлык кухняларда да диярлек түшәмнәр штукатураланмыйча калдырылды.

Шәһәрчектә 5—6 меңгә якын эшче һәм хезмәткәр тора. Алар шәһәрчекне су белән тәэмин итүне яхшырту турында торак йортлары идарәсенә һәм комбинат житәкчеләренә күп тапкырлар мөраҗәгать иттеләр инде. Ләкин аларның бу урынлы таләпләре тормышка ашырылмый. Барлык корпусларның да өченче һәм дүртенче этажларында су бөтенләй булмый. Еш кына вакыт шәһәрчектә су эзләп йөрергә туры килә. Водоканал үз бурычын үтәүгә җавапсыз карый. Ул су белән тәэмин итү турында төзелгән договорны үтәми. Комбинатның коммуналь торак йортлары идарәсе начальнигы иптәш Малов „договор төзелгән, шулай булгач су булырга тиеш" дип тыныч кына йөри бирә.

1940 нчы елның ике ай ярым вакты эчендә ягулыкка 50 мең сум артык расход тотылды. Шулай булуга карамастан, байтак квартиралар салкын. Беренче корпусның 31 нче квартирасында торучы Симагина һәм Яббаров иптәшләр квартираның салкын булуыннан зарланалар. Ягулыктан дөрес файдалана белмәү нәтиҗәсендә пар батареяләре шартлау фактлары да булды.

Квартира бәяләрен үз вактында җинауга тиешенчә әһәмият бирелми. Йортларда торучыларның кайберләре дүртәр-бишәр ай буенча квартира хакы түләмиләр. Бишенче корпуста торучы Исмагыйлов 1.000 сум, икенче корпуста торучы Щербакова 400 сум һәм дүртенче корпуста торучы Әбҗалимов 355 сум квартира акчасын түләмәгәннәр.

Шәһәрчектә торучы эшчеләргә культура хезмәте күрсәтү канәгатьләнерлек түгел. Мехкомбинатның партия һәм профсоюз оешмалары социалистик шәһәрчектә культуралы һәм җиһазландырылган кызыл почмак булдыру турында аз сөйләнмәделәр инде. Ләкин шушы көнгә кадәр бу мәсьәләне практик хәл иткәннәре юк әле.

Шәһәрчектә кер юу урны, парикмахерская һәм телефон будкасы булдырырга күптәннән вакыт инде. Бу турыда карарлар да бар. Ләкин эш кенә күренми.

Мехкомбинат җитәкчеләре социалистик шәһәрчектә булган кимчелекләрне белү, ишетү һәм фактларны теркәп кую белән генә чикләнәләр. Шәһәрчекне чын мәгънәсе белән культуралы, төзек хәлгә китерү өчен мөмкинлекләр зур. Бары тик игтибар һәм тиешле кайгыртучанлык күрсәтү генә кирәк.

К. Хөсни.

ЮЛЛАР ТӨЗЕЛЕШЕНДӘ

Алдынгылардан үрнәк алыйк

Арча районының күп кенә колхозлары Ферганә каналын төзүчеләрнең бай тәҗрибәләрен юл төзелешендә файдаланалар. Юл төзелеше алдынгылары төзү материаллары хәзерләүнең айлык планын арттырып үтиләр. Мәсәлән, „Кызыл Кырлай" колхозы төзү материаллары хәзерләүне һәм аларны участокларга ташуны срогыннан алда үтәде. Юл төзелешендә эшләүче бригаданың бригадиры иптәш Дәүләтбаев яхшы үрнәк күрсәтә. Колхозчылардан Хәмидуллин, Шәйдуллин, Саттаров һәм Гыйлметдинов иптәшләр таш чыгаруда нормаиы 150 процент итеп үтиләр.

Алдынгы колхозлар белән бергә, әле бу әһәмиятле эшкә игтибар биреп җиткермәүче колхозлар да бар. Куйбышев исемендәге колхоз төзү материаллары ташу планын бары 10 процентка гына үтәде. Колхоз председателе иптәш Мосагитов үз бурычын үтәүгә җавапсыз карый. „Кызыл Көтек" колхозының төзү материаллары кар астында ята.

Культуралы һәм үрнәкле юллар төзү өчен бездә мөмкинлекләр зур. Эчке мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланып, 1940 нчы елгы юл төзелеше планын районның барлык колхозлары буенча үтәргә һәм арттырып үтәргә кирәк. Район җитәкчеләре Ферганә тәҗрибәсен юл төзелешендә киң куллану өчен колхозларга булышлыкны көчәйтергә тиешләр.

М. Галиев.

Продукциянең сыйфатына игтибарны көчәйтергә

Киез итек-фетр фабрикасы январь ае планын 103,1 процент итеп, февраль ае планын 100,1 процент итеп үтәде. Март аенда да планның үтәлеше начар түгел. Стахановчылардан Гобәева, Сабирова, Сафина, Закирова һәм башка күп кенә иптәшләр норманы икешәр-өчәр тапкыр арттырып үтиләр. Алар орденлы Татарстан республикасының XX еллык бәйрәмен производствода яңа уңышлар белән каршылау өчен нык көрәш алып баралар.

Ләкин продукциянең сыйфатын яхшырту өчен әле бик нык эшлисе бар. Фабриканың күп кенә цехлары күп кенә хәлләрдә сан артыннан куып, продукциянең сыйфатын яхшыртуга тиешле әһәмият бирмиләр. Моның нәтиҗәсе яхшы түгел, әлбәттә. Фабрика киез итек буенча 75 процент, фетр буенча 75 процент беренче сортлы продукция җитештерергә тиеш иде. Ләкин сортлар буенча план үтәлми. Январь аенда беренче сортлы киез итек 57 процент, февраль аенда 55 процент, беренче сорт фетр январь аенда 62, февраль аенда 60 процент кына булды. Ә өченче сортлы продукция күтәрелде. Фабрика җитәкчеләре беренче сортлы продукция җитештерү турында приказ чыгару белән генә чикләнәләр. Приказларның үтәлешен тикшерү белән шөгыльләнмиләр.

Фабрика җитәкчеләре, партия һәм профсоюз оешмалары планны сыйфат ягыннан тулы үтәү өчен бөтен чараларны күрергә тиешләр.

Х. Галиев.

ПРОИЗВОДСТВОГА БОЛЬШЕВИСТИК КОНТРОЛЬ

...артия оешмалары предприятие администрациясенең эшенә контроль ясауны дөрес оештыр... урыннарда производство ...нарны тулы һәм арттырып ...ә, коммунистларның авангард рольләре көчәя, партиясезләр ...н элемтәләре ныгый, партия...итик эшнең гомуми дәрәҗәсе ...н да күтәрелә.

...роизводствога контрольлек ...е оештыру буенча 5 нче ме...ика заводы һәм 4 нче мех ...рикасы янындагы партоешма...ың беренче тәҗрибәләрен ...сәтеп үтәргә мөмкин.

... нче механика заводында ...изводство планы шактый ва... үтәлми килде. 1939 нчы ел... февраль—март айларында ... бу эштә борылыш була...лады. Партиябезнең XVIII нче ...ды алдыннан оештырылган ...ш моңа зур этәргеч булды. ...еләр һәм инженер-техник ра...иклар арасында производство ...влыгының яңа күтәрелеше ... Завод коллективы еллык ...ны срогыннан 4 ай элек арт...ып үтәүгә ирешә. Бу завод ... да айлык производство ...нарын системалы рәвештә ...ырып үтәп бара. Хәзер пред...тие коллективы СССР Вер...ый Советының VI нчы ...сиясен яңа уңышлар белән ...ы алу өчен көрәшә.

...водта бу җидди борылышны ...да башлангыч партоешманың ...етаре иптәш Кузнецов) җи...елеге хәл иткеч роль уйна... Завод партоешмасы производ... планын тулы үтәүне тәэмин ... өчен өзеклекнең төп сәбәпләрен табарга тиеш иде. Һәм ул моны коммунистлар һәм партиясез активистлар ярдәме белән тапты. Партия оешмасы үз алдына төп бурыч итеп производствода хезмәтне яңача оештыру мәсьәләсен куйды. Чөнки планны тулы үтәүне тәэмин итү өчен, барыннан да элек, хезмәт процессын бүгенге таләпләргә җавап бирерлек итеп оештырырга кирәк иде. Һәм ул шулай эшләнде: эш нормалары яңача төзелде, яңа техник чаралар үткәрелде. Барлык коммунистлар һәм партиясез активистлар, цех начальниклары һәм мастерлар, массага яңа нормаларны аңлату эшен алып баруга, хезмәтне большевикларча оештыруга тупланды. Производстводагы җитәкче постлар яңа, эшлекле кадрлар белән ныгытылды. Цехларда һәм бүлекләрдә партия-масса эшләрен ничек алып бару мәсьәләсе коммунистлар һәм партиясез активистлар катнашы белән тикшерелде. Политик-агитация эшен завод алдында торган конкрет бурычларга бәйләп алып баруга аеруча әһәмият бирелде. Коммунистлар производствода үзләренең авангардлык рольләрен күтәрү өчен үзара ярышны көчәйттеләр. Турыдан-туры производствода эшләүче коммунистларның барсы да стахановчы булуга ирешелде. Коммунистлар производствода алдынгы булу белән бергә, үз тәҗрибәләрен башкаларга күчерү һәм тулай бригадаларны, цехларны алдынгы итү буенча да нык көрәш алып баралар.

Партия оешмасы предприятие администрациясе эшенә контрольне системалы рәвештә алып бара. Партоешма эш барышыннан чыгып күп кенә практик мәсьәләләрне хәл итә һәм хуҗалык җитәкчеләренә теге яки бу эшне оештыру буенча конкрет юнәлеш бирә. Заводта продукциянең сыйфаты өчен көрәшне көчәйтергә кирәк иде. Партоешма бу мәсьәлә буенча техдиректорның докладын тыңлады һәм конкрет карар кабул итте. Бераз вакыттан соң партоешма бу карарның үтәлешен тикшерүне оештырды. Яш коммунистлардан фрезеровщик Курилов һәм Тимофеев иптәшләргә, кою цехының начар эшләү сәбәпләрен тикшерү эше тапшырылды. Аларның тикшерү нәтиҗәләре җыелышка куелды. Кою цехында бракка каршы көрәшне көчәйтү өчен яңа техник чаралар билгеләнде. Брак ясаучы эшчеләр белән аерым беседа оештырып, аларга алдынгыларның тәҗрибәләре аңлатылды һәм аларның эшенә контроль көчәйтелде. Шуннан соң бу цехта эшнең сыйфаты нык кына яхшырды.

4 нче мех фабрикасындагы партоешма да производствога контроль оештыру буенча шактый эшләр үткәрде. Предприятие администрациясенең эшенә системалы рәвештә контрольлек итү фабриканың алдынгылар сафына басуына зур ярдәм итте. Фабрика 1939 нчы елның беренче квартал планын 71 процентка гына үтәгән иде. ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын пропагандалау эшен производство бурычларына бәйләп алып бару нәтиҗәсендә бу өзеклек бетерелде. Партия оешмасы предприятие җитәкчеләренең игтибарын конкрет бер мәсьәләгә—хезмәтне дөрес оештыру мәсьәләсенә юнәлдерде. Бу турыда партия җыелышында тикшергәннән соң, барлык цехларда киңәшмәләр үткәрелде. Партоешма карары һәрбер эшчегә җиткерелде. Социалистик ярыш договорлары яңартылды. Партоешма карарларның үтәлешен көн саен тикшереп барды. Карарларның үтәлешен еш тикшерү һәм эш барышында килеп чыккан кимчелекләрне вактында бетерүгә ярдәм итү предприятиенең көннән-көн яхшы эшләвен тәэмин итте. Фабрика коллективы үзенең яхшы эш үрнәкләре белән Мехкомбинатның күчмә кызыл байрагын яулап алды. Стахановчылар мәктәбенең эшен яхшы оештыруы өчен фабрикага СССР Җиңел Промышленносте наркоматы күчмә кызыл байрак бирде. Менә болар хуҗалык бурычларын политик-масса эшләре белән нык бәйләп алып баруның конкрет нәтиҗәләре булып торалар.

Партоешма рационализаторлар хәрәкәтен җәелдерүгә аеруча игтибар бирә. Фабрикада рационализация эше киң урын алган. Рационализаторларның үзләренә аерым стена газетасы чыгарыла, бирелгән тәкъдимнәрен һәм аларның нәтиҗәләрен массага күрсәтү өчен махсус витрина алып барыла. Коммунистлардан һәм партиясез иптәшләрдән күп кенә новаторлар бар. Коммунист иптәш Касмасовның тәкъдиме елына 100 мең сумнан артык экономия бирә. Хәзер ул баш киемнәрен футорлау өчен электрик форманы куллану өстендә тәҗрибә алып бара. Бу механизацияне кертү хезмәт җитештерүчәнлеген кимендә 2—3 тапкыр арттыруга һәм бик күп экономия ясауга мөмкинлек бирәчәк. Коммунистлардан Ступишин, Грачев, Михеева, Люткина һәм партиясезләрдән Коротков, Емельянов, Каратаев, Круглов, Сладков һәм башка иптәшләр күп кенә кыйммәтле тәкъдимнәр керттеләр. Иҗади инициативаның бу гүзәл үсеше—партия оешмасының коммунистларда, барлык эшчеләрдә бик кыйммәтле большевистик сыйфат—яңалыкны сизү сыйфатын тәрбияләүгә нык әһәмият биргәнлеген күрсәтә.

Предприятие администрациясенең эшенә контрольлек итү буенча ирешелгән беренче тәҗрибәләр бу мөһим чараның гаять зур әһәмияткә ия булуын, хуҗалык бурычларын политик эш белән бәйләп алып баруга зур ярдәм итүен бик ачык күрсәтәләр. Хәзер бурыч—бу беренче уңышларны ныгытудан, производствога большевистик контрольлек итү хокукын барлык предприятиеләрдә тулы тормышка ашырудан гыйбарәт.

5 нче механика заводы һәм 4 нче мех фабрикасы Мехкомбинатка берләшкән предприятиеләр. Ләкин Мехкомбинат үз системасындагы бу предприятиеләрнең тәҗрибәләрен башкалар белән уртаклашуга, уңышларны ныгытуга җитәрлек игтибар бирми. Комбинатта үткән елны производство планын срогыннан алда үтәп чыгу уңышы белән тынычлану нык сизелә. 1 нче, 2 нче һәм 3 нче фабрикаларның 1940 нчы елның башында планнарны үтәми башлаулары моны ачык күрсәтә. Үткән елгы уңышлар белән тынычлану фактлары барлыкны коммунистлар партоешманың отчет-сайлау җыелышында әйткәннәр иде. Ләкин комбинат партбюросы җыелыш карарыннан үзенә кирәкле нәтиҗәне ясап җиткермәгән. Партбюро алдынгыларның тәҗрибәләрен башкаларга күчерергә, производствога большевистик контрольне көчәйтергә тиеш. Комбинатның быел да производство планын тулы һәм арттырып үтәү өчен бөтен мөмкинлекләре бар. Алдынгыларның тәҗрибәсе моны ачык күрсәтә.

У. Ахметов.

МЕХАНИЗАТОРЛАР ЯРЫШЫ

Казан пристаненең механизация эшчеләре Татарстан республикасының XX еллыгын яңа уңышлар белән каршылау өчен алган йөкләмәләрен намус белән үтиләр. Моторларга ремонт ясау эше график буенча 10 нчы апрельгә тәмам булырга тиеш иде. Механизация коллективы бу йөкләмәне 5 нче апрельгә тәгәлләү өчен ныклы көрәш алып бара. 65 мотордан 58 моторга ремонт ясау тәмам булды инде. Кабул итү комиссиясе моторларга ясалган ремонтның отлично һәм яхшы сыйфатлы булуын әйтте.

Транспортерларга ремонт ясау эше элегрәк нык артка калып бара иде. Матбугатта бу турыда сигналлар булганнан соң күп кенә чаралар күрелде. 10 нчы мартка 12 данә транспортерга ремонт ясалды. Ремонтның сыйфаты яхшы.

Стахановчылар хезмәт җитештерүчәнлегенең югары үрнәкләрен күрсәтәләр. Слесарьлардан Светов, Спиридонов, балта осталарыннан Сергеев, Фокиев һәм башка иптәшләр үзләренең нормаларын 200 процент итеп үтиләр. Зиннәтуллин, Димитриков, Гыйматуллин, Чупилин, Парфинович иптәшләр дә алардан калышмыйлар.

Ф. Исхаков.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮ АЛДЫННАН

Яз килә!

АЛЕКСЕЕВСКИЙ, 25 март. (Махсус хәбәрчебездән телефон буенча). Йомшак ак кар астында яткан җир битләре ялангачлана башлады. Язгы кояш нурлары көннән-көн көчәя. Һавада җылылык. Җирдә җанлылык. Кешеләрнең, машиналарның киң басуларга чыгу көннәре якынлаша. Яз килә!

Киң кырларда хөкем сөргән кышкы тынлык тиздән көчле хезмәт симфониясе белән алмашыр. Һәр көн, һәр сәгат алтыннан да кыйммәтле! Сталинчыл уңыш алу өчен, язгы чәчүне үрнәкле үткәрү өчен көрәш тагын да көчәергә тиеш.

Алексеевский районының „Кызыл Шәрык“ совхозы коллективы да язны уңышлы үткәрүгә хәзерләнә. Совхоз чәчүгә канәгатьләнерлек хәзерләнгән. Чәчү орлыклары җитәрлек. Чиста. Аның тишелешен дә сынап караганнар. Тишелеш уртача 90—95 процент. Басуга ике мең тоннадан артык тирес чыгарылган, кар тоту планы 111 процентка, көл җыю планы 200 процентка үтәлгән. Тракторларга һәм тагылма инвентарьларга ремонт нигездә төгәлләнгән. Бу совхоз белән ярышучы „Спартак“ совхозыннан килгән делегация ремонтның сыйфатын яхшы дип тапты. Тракторлар паркы өчен ягулык һәм майлау материаллары ташып куелган. Атлар чәчү эшенә хәзер. Азык җитәрлек.

Шулай да совхоз коллективы бу уңышлар белән генә тынычланмый. Язгы чәчүгә хәзерлекне кат-кат тикшерә, кимчелекләрне эш барышында ук бетерә бара. Чәчүне югары сыйфатлы итеп 7—8 эш көнендә төгәлләү өчен, гектарыннан уртача 14—15 центнер уңыш алу өчен практик чаралар күрелә.

Совхозда уннарча стахановчылар кичке курста укып, ефремовча уңыш алу методларын өйрәнәләр. 3 ефремовчы звено оештырылган. Бу звенолардагы эшчеләр махсус курс аша үткәреләләр.

Совхоз үз эшләренең техникасын яхшы үзләштергән кадрлары белән бик урынлы мактана. Кырчылык эше бригадиры Бобров, чәчүче Матвеев, Седонин, мастерской мөдире Тимофей Бобров, слесарь Фомин һәм башка иптәшләр чәчүгә хәзерлектә үзләрен үрнәкле эш белән танытканнар. Алдынгылардан 13 кеше Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашу өчен кандидат итеп күрсәтелделәр. 3 кеше республикабызның Почет Тактасына кертелде. Быел 16 кеше тракторчылар курсында укыды.

Совхоз директоры Саймонов, политбүлек начальнигы Җиһаншин иптәшләр язгы чәчү чорында политик-масса һәм культура эшләрен оештыруга зур игтибар бирәләр. 28 кешедән торган агитколлектив бар. Һәрбер агитатор конкрет эшкә һәм аерым участкыга беркетелгән.

Чәчү вактында ике җирдә культвагон, ашханә булачак. Кирәкле продуктлар инде хәзерләнеп тә куелды.

„Кызыл Шәрык“ совхозы язгы чәчүгә әнә шулай оешкан рәвештә килә.

К. Биков.

ИСКЕЧӘ ЭШЛИ ТОРГАН ҖИР БҮЛЕГЕ

Район җир бүлекләренә гаять катлаулы һәм җаваплы эш йөкләнгән. Алар районнарда авыл хуҗалыгының сугышчан штабы ролен уйнарга тиешләр. Моның өчен район җир бүлекләре работникларының яхшы эшләве белән бер рәттән, аларның эшенә партия, совет оешмалары тарафыннан көндәлек булышлык, большевистик җитәкчелек таләп ителә.

Ләкин әле бу таләп барлык районнарда да үтәлә дип булмый. Мисалга Чепья районын алыйк. Бу районның җитәкче оешмалары район җир бүлегенә, аның эшенә әһәмият бирмиләр. Район советының башкарма комитеты райзоны мәгълүматлар кирәк булганда гына искә төшерә. Район җир бүлеге исә һаман да искечә эшли, ул үзенең эшен СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары буенча үзгәртеп кормаган. Штат ныгытылмаган. Белгечләр җитми, булганнары күп вакытларын канцеляриядә, райком һәм район советы башкарма комитеты өчен саннар җыю, сводка тутыру белән үткәрәләр.

— Миңа,—ди өлкән зоотехник иптәш Горшков,—күп вакытта статистик булып утырырга туры килә, эш башкаручы эшен дә мин алып барам. Чөнки статистик үзенең эшен алып бара алмый, эш башкаручы бөтенләй юк. Иртәнге сәгат 8 дән төнге сәгат 11 гә чаклы эшләүгә карамастан, үземнең төп эшем белән шөгыльләнергә җитәрлек вакыт калмый.

Райзоның өлкән агрономы иптәш Гавриловның да күбрәк вакыты канцеляриядә утырып үтә. Урынга барып, колхоз производствосына практик булышлык итүне Чепья район җир бүлегендә онытып баралар инде.

Бу хәл, кабатлап әйтергә кирәк, барыннан да элек, район советы башкарма комитетының райзога җитәкчелек итмәве, аның эшенә контроль ясамавы, аның эше турында, анда эшләүче работниклар турында онытуының нәтиҗәсе булып тора.

Район җир бүлеге белгечләре өчен нормаль эш һәм тормыш-көнкүреш шартлары тудыру турында да район оешмалары кайгыртучанлык күрсәтмиләр. Менә өлкән агроном иптәш Гавриловның эш кабинеты. Биредә ике кеше утыра. Ул шул кадәр кечкенә, ике өстәл, ике урындык куйгач, анда борылырга да урын калмый. Иптәш Гавриловның квартира шартлары да бик начар.

Чепья район җир бүлегенең бу килеш эшләве кайчанга кадәр дәвам итәр икән? **Х. Галләмев.**

МТС ЭШЕ ТУРЫНДА... РАЙЗО ОТЧЕТ ЯСЫЙ?

АЗНАКАЙ. (Телефон буенча). Кәкре елга МТС ы язгы чәчүне хәзерлексез каршылый. МТС та трактор һәм тагылма коралларга әле дә ремонт төгәлләнмәгән. 19 тракторга капитал ремонт һәм 10 тракторга агымдагы ремонт үткәреләсе бар. Трактор бригадалары кайсы участокда эшләячәкләрен белмиләр, аларның эш планнары да юк әле. МТС җитәкчеләре, ремонтның начар баруын запас частьләрнең җитешмәвеннән һәм Бөгелмә МТМ ының начар эшләвеннән килә, дип күрсәтмәкче булалар. Артта калуның сәбәпләрен читтән эзләү монда гадәткә кергән булса кирәк. ВКП(б) райком секретаре иптәш Закиров Наркомземны гаепли. Билгеле, Наркомземның МТС ка җитәкчелеге канәгатьләнерлек түгел. Ләкин артта калуның төп сәбәпләре МТС ның үзендә дә бик күп.

Менә фактлар. Ремонт эшчеләре арасында социалистик ярыш тиешенчә оештырылмаган, хезмәт дисциплинасы түбән, 40—50 кеше эшлисе урынга, эшкә бары 10—15 кеше чыга. Тракторчы Талипов үзенең тракторына ремонт ясауны бер айдан бирле тәмам иткәне юк.

Отчет бирү һәм 1940 нче ел өчен колхозлар белән договор төзү 15 нче мартта гына башланды. Район җир бүлеге, ВКП(б) райкомы МТС җитәкчеләреннән ул эшне вактында үткәрүне таләп итү һәм аны оештыруда аларга ярдәм күрсәтү урнына, колхозларда отчет бирү, колхозлар белән договор төзү эшен район җир бүлеге работникларына һәм район активына тапшырганнар. Шулай итеп, райзо работниклары МТС өчен отчет биреп йөриләр, договорлар төзиләр. Ә МТС җитәкчеләре читтән генә күзәтеп торучы булып калганнар. МТС ның язма отчеты күбрәк уңышлар турында сөйли, ә кимчелекләрне колхозчылар әйтергә тиеш булып чыга. **З. Салахеттинов.**

ДАИМИ ЗВЕНО ҺӘМ АНЫҢ ЭШЕ

Безнең звенода 7 кеше. Шуларның 2 се ир, 5 се хатын-кыз. Быелгы эш сезоны өчен безнең звенога 22 гектар пар һәм чәчү мәйданы беркетелде. Чәчү мәйданының ефремовча уңыш участкысында 5 гектар солы, 5 гектар борчак һәм 2 гектар тары булачак. Билгеле, югары иген уңышы алу, барыннан да элек, агротехника чараларын җиренә җиткереп үтәүгә бәйләнгән. Без эшнең әнә шул ягына нык әһәмият бирәбез.

Безнең звено барлык мәйданда 60—70 сантиметр тирәнлектә кар тотты һәм 5 гектар чамасы җирдә кар суларын саклап калу чарасын үткәрә. Һәр гектарга 20 тоннадан артык тирес чыгардык һәм игеннәрне тукландыру өчен җитәрлек күләмдә кош тизәге, фекаль ашламасы һәм мульчировать итү өчен кара тирес хәзерләп куйдык.

Ефремовча уңыш алу участкылары өчен кирәкле чәчү орлыкларын кулдан сайлап чистарттык. Шулай итеп, солыны һәр гектарга 1,5 центнер, борчакны 1,4 центнер һәм тарыны 0,16 центнер чәчү өчен орлык хәзерләп куйдык. Солыны һәм тарыны формалин белән акулап, борчакны нетрагинлап чәчәбез.

Чәчүне үткәрү, игеннәрне тәрбияләү һәм пар сөрү эшләрен агротехника кагыйдәләренә туры китереп үткәрүне без алдан планлаштырдык һәм шуны тормышка ашыру өчен көрәшәбез. Хәзер туфракның өлгерүен һәр вакытта күзәтеп торабыз. Туңга сөрелгән җирләрне культивацияләү һәм тырмалау эшләрен ике көндә, солы һәм борчак культураларын чәчүне 3 көндә төгәлләүне планлаштырдык. Борчакны туфракка 6—7 сантиметр, солыны 5—6 сантиметр, тарыны 2—3 сантиметр күмдереп, борчакны киң рәт белән, солыны шакмаклап чәчәбез. Чәчү беткәч тә 2 гектар солы мәйданы өстендә 1—2 сантиметр калынлыкта мульчировать итү һәм ефремовча уңыш алу билгеләнгән барлык мәйдандагы игеннәргә ике тапкыр тукландыру үткәрәчәкбез. Игеннәрнең үсү дәверендә аларны һәр вакыт чүп-үләннәрдән чистартып торачакбыз.

Урып-җыю, пар җирен эшкәртү һәм көзге чәчү эшләрен башкару буенча да агротехника чараларын үткәрүнең конкрет планын төзедек. Безнең звено 10 нчы бригаданың ефремовча иген уңышы алырга йөкләмә алган иптәш Әхмәдишин звеносы белән ярыша.

Гөлчирә Мурзина.

Актаныш районы, „Кызыл көч“ колхозының 2 нче бригадасында звено җитәкчесе.

Юдино район җир бүлеге тарафыннан оештырылган умартачылар хәзерләү курсында. Укучылар курс җитәкчесе зоотехник иптәш Г. И. Бажановның лекциясен тыңлыйлар.

И. Галиев фотосы.

БАЛТАЧТА КАЙЧАН ТӘРТИП УРНАШЫР?

Җәмәгать терлекчелеген үстерү чаралары турында СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары авыл хуҗалыгының бу тармагын тагын да алга җибәрү өчен көчле этәргеч булып тора. Ләкин, Балтач районында бу карарны тормышка ашыруга җидди игтибар бирелми. Райондагы товарлыклы-сөтчелек фермаларына үткәрелгән тикшерү Балтач район җир бүлегенең һәм аның зоотехникларының районда мондый ничә ферма барлыгын гына белүләрен, ә ул фермаларда эшнең ничек барышы белән бөтенләй таныш түгеллекләрен күрсәтте.

Без райондагы товарлыклы-сөтчелек фермаларының 5 ндә үткән елны күпме сөт алынуын һәм сөтнең нинди кирәкләргә тотылуын тикшердек. Тикшерү түбәндәге нәтиҗәне бирде: „Кызыл Чишмә“ колхозында (Түбән Кнә авыл советы) үткән елны локтация чорында һәр сыердан 846,9 литр, „8 нче Март“ колхозында (Югары Шуган авыл советы) 452,2 литр, Калинин исемендәге колхозда (Арбаш авыл советы) 589 литр, „Кызыл Көч“ колхозында (Хәсәншәех авыл советы) 473 литр, „Көрәш“ колхозында (Таузар авыл советы) 632,6 литр сөт савып алынган.

Бу колхозларның бөтенесе дә район үзәге Балтачка уртача 5 километр ераклыкта. Терлек азыгы булдыру һәм гомумән терлекчелекне үстерү өчен алардагы шартлар да тигез. Шулай булгач, беренчедән, бу колхозларда сыерларның сөт бирүләре ни өчен бик түбән һәм, икенчедән, алардагы күрсәткечләрдә ни өчен аерма болай бик зур, дип бирелгән сорауга, без Балтач район җир бүлегендә җавап таба алмадык. Бик озак уйлап торганнан соң, безгә район җир бүлегенең өлкән зоотехнигы иптәш Шакиров, үткән елны безгә Татнаркомзем сыерларның сөт бирүләрен учетка алып бару формасын җибәрмәде, шуңар күрә андый учетны алып бармадык, дип җавап бирде.

Тикшерелгән бу фермаларда бозауларга сөт эчерү буенча норманы да һәрбер ферма үзенчә билгеләгән. Калинин исемендәге колхозда сөт эчерү чорында һәрбер бозауга 219 литр, „Көрәш“ колхозында 285,6 литр, „8 нче Март“ колхозында 90 литр сөт эчерелгән.

Фермаларда сөткә төгәл учет булмау, район җир бүлеге тарафыннан контроль ясалмау нәтиҗәсендә югарыда күрсәтелгән колхозларда сөтнең урлануы өчен, кирәксез урыннарга таратылуы өчен уңайлы шартлар килеп чыккан.

Югарыда күрсәтелгән колхоз фермаларында 1938 нче елда дәүләткә 33 мең 886 литр, үткән елны 62 мең 286 литр сөт тапшырылмый калган. Ә шул ук вакытта бик күп сөтне базарга чыгарып сатканнар. „Кызыл Чишмә“ колхозы үткән елны дәүләткә сөт тапшыру буенча 2 мең 895 литрга бурычлы булып калган, ә шул ук вакытта 6 мең 153 литр сөтне базарга чыгарып саткан. „Көрәш“ колхозы 4 мең 236 литр сөтне базарга чыгарып саткан һәм шул ук вакытта дәүләткә тапшырыласы сөтнең 11 мең 609 литрын тапшырмый калдырган.

Районда дәүләткә сөт тапшыру планын үтәүне оештырмаган өчен 1939 нчы елның 29 нчы сентябрендә Татсовнарком карары буенча Балтач район советы башкарма комитеты председателе Закиров һәм райуполнаркомзаг Майоров иптәшләргә выговор бирелгән иде. Шул ук вакытта бу карарда Татнаркомземга һәм район җир бүлегенә колхоз фермаларында эшне тәртипкә салырга, бигрәк тә сыерларның сөт бирүләрен арттыру һәм сөтне учетка алу эшләрен оештырырга, дәүләткә сөт тапшыру эшен тулысынча үтәү өчен көрәшергә тәкдим ителгән иде. Ләкин Балтач район җитәкчеләре дә һәм Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты җитәкчеләре дә Совнаркомның бу карарын үтәмәделәр.

Балтачта кайчан тәртип булыр һәм Балтач район җитәкчеләрендә дәүләт йөкләмәләрен үтәүгә ихтирам белән караш кайчан урнашыр соң? **Петров.**

Колхозара ярдәмләшү

Минзәлә районы колхозларында чәчү орлыклары белән үзара ярдәмләшү киң җәелде. „Возраждение“ колхозы членнары „Красный пахарь“ колхозына бурычка 61 центнер чәчүлек солы бирделәр. Аерым колхозчылардан иптәш Фрол Изряднов 2 центнер һәм иптәш Михаил Архипов 1 центнер, барлыгы 7 хуҗалык 11,6 центнер орлык бирде.

Минзәлә колхозында 1.535 центнер чәчүлек орлык җитешми. „Яңа юл“, „Алга“ һәм „Күргәзмә“ колхозлары аңа үзара ярдәмләшү тәртибендә югарыда күрсәтелгән күләмдә чәчүлек орлыклар бирәләр.

Ефремовчылык хәрәкәтен киң җәелдерик

Колхозларда даими звенолар оештыру—ул, иген уңышын күтәрү өчен звено членнарына җирнең һәрбер участкысының үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнүеп эш итүгә зур мөмкинлекләр бирә. Звено инициатива күрсәтү, тәҗрибәне уртаклашу һәм уйлап табучылыкны киң җәелдерү өчен шартлар тудыра. Звенолар төзү—ул, колхозчылар массасын тәрбияләү, аларны үз эшләренең энтузиастлары итеп әверелдерү, яшьләрне дә һәм картларны да югары иген уңышы мастерлары белеме дәрәҗәсенә күтәрү, агротехника чараларын тулысынча үтәү һәм арттырып үтәү өчен киң мөмкинлекләр ача.

Партиянең XVIII нче съездында иптәш Молотов авыл хуҗалыгында звеноларның гаять зур урын тотканлыкларын ачык итеп күрсәтте. Иптәш Молотов болай диде: „Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә һәм авыл хуҗалыгын үстерүдә инде колхозларда звенолар төзү зур роль уйнады. Хәзергә әле звенолар оештыру колхозларның бер өлешендә генә җәелгән. Хәлбуки бу эшнең файдалы икәнлеген тәҗрибә күрсәтте һәм аны колхозларда киң күләмдә җәелдерергә кирәк“.

Эшне звенолап оештыру буенча бездә бай тәҗрибә бар. Бу өлкәдә Алтай крае авыл хуҗалыгы стахановчыларының тәҗрибәләре бигрәк тә зур. Алар иген уңышын күтәрүдә үрнәк булырлык күрсәткечләргә ирештеләр. Мәсәлән, узган елны иптәш А. С. Сергеева звеносы рекорд участкыда сабан бодаеның һәр гектарыннан 606 пот, Славгород районының „Утро Мая“ колхозында иптәш Черногор звеносы рекорд участкыда һәр гектардан 475 пот, ә звенога беркетелгән 51 гектарның һәр гектарыннан уртача 183 пот бодай, Солтон районының „Майское утро“ колхозында иптәш Вязмин звеносы уҗым бодаеның һәр гектарыннан 311 пот уңыш алдылар.

Бу фактлар иген уңышын күтәрүдә даими звеноларның зур урын тотканлыкларын бик ачык күрсәтәләр.

Шушы бай тәҗрибәдән файдаланып һәм партиянең XVIII нче съезды күрсәтмәләрен тормышка ашыру йөзеннән, 1939 нчы елны Татарстанның 42 районында 23 меңнән артык даими звено төзелгән иде. Ләкин партиянең район оешмалары, совет һәм җир органнары тарафыннан тиешле ярдәм һәм ныклы җитәкчелек булмаган урыннарда аларның күбесе таралды. Звеноларны оештыру эшендә җидди кимчелекләр булды. Звенолар зур итеп, 12—16 кешедән оештырылдылар. Бу хәл, әлбәттә, звенога җитәкчелекне кыенлаштырды һәм эштә иясезлек тудырды. Кайбер урыннарда кырда эшләмәүче колхозчыларны, мәсәлән, сторожларны, ат караучыларны һәм башкаларны да звено составына керттеләр. Һәрбер звенога чәчү әйләнешенең барлык кырларыннан да культуралар беркетелде. Бу хәл исә культураларның мәйданын ваклауга һәм хезмәтнең җитештерүчәнлеген киметүгә китерде. Аннары звеноларны сезонлап (язгы чәчү, чүп утау, урып-җыю чорына һ. б.) яки эшнең аерым тармаклары буенча (сабанчылар, чәчүчеләр, тырмачылар звенолары һ. б.) төзү фактлары да булды.

Мондый звенолар даими звено була алмыйлар, аларда югары иген уңышы алуны тәэмин итәрлек эш шартлары тудырып булмый. Шуның өстенә кайбер звеноларда хезмәтнең һәм уңышның учеты да тиешенчә оештырылмаган иде.

Алтай крае колхозларында звеноларны оештыру формаларын һәм аларның производство тәҗрибәләрен һәр яклап өйрәнгәннән соң, Татарстан колхозларында звеноны 7—10 кешедән оештыру яхшырак булыр дигән нәтиҗәгә киленде.

Социалистик игенчелеккә яңалык кертүче М. Е. Ефремов һәм И. Е. Чуманов иптәшләрнең колхозларында звенолар ничек оештырылган соң?

Монда Алтай крае колхозларыннан берничә мисаль китерергә кирәк. Менә Белоглазово районындагы „Молодая Гвардия“ колхозы. Бу колхозда 3 кырчылык бригадасы бар. Һәрбер бригадада икешәр звено оештырылган: шуның берсе ефремовчы звено, икенчесе даими гади звено.

1939 нчы елны беренче бригаданың беренче звеносы 13 кешедән төзелгән. Аңа 178 гектар бодай, 15 гектар солы һәм 10 гектар тары беркетелгән. Бригаданың икенче звеносы 14 кешедән тора. Аңа 100 гектар бодай, 25 гектар солы һәм 12 гектар тары беркетелгән.

Бестужево авыл советының „Новый Чарыш“ колхозы 88 хуҗалыкны берләштерә. Монда хезмәткә яраклы 159 кеше бар. Колхозның чәчүлек мәйданы 2.300 гектар. 72 баш эш аты бар (колхозга МТС хезмәт күрсәтә). 1939 нчы елны монда бригадалар һәм звенолар арасында чәчүлек мәйданы менә болай бүленгән булган:

Беренче бригадага 345 гектар сабан бодае, 99 гектар солы, 17 гектар тары, 35 гектар көнбагыш, 2,3 гектар кудряш җитен, 2,9 гектар киндер, 2,7 гектар бәрәңге һәм 7 гектар Америка саруты (барлыгы 510,9 гектар) чәчүлек мәйданы беркетелгән. Бригадада 5 звено бар: берсе ефремовчы звено, 4 се даими гади звенолар. Ефремовчы звено 5 кешедән тора. Аңа 13 гектар бодай беркетелгән. Даими гади звеноларның берсендә 12 кеше, башкаларында 13 әр кеше. Аларга да чәчүлек мәйданнары көчләренә карап беркетелгән.

Звеноларның составы 1940 нчы елны да үзгәрми. Ләкин ефремовчы звеноларның җир мәйданы 50 гектарга кадәр җиткерелә.

Бәрәңге, җитен һәм үләннәрнең звеноларга беркетелми калуын бу колхозларның звенолар оештыруда зур кимчелекләре дип исәпләргә кирәк.

Сорокин районындагы „Украина“ колхозының тәҗрибәсе тагын да кызыграк. Иптәш С. Андросова звеносы (7 кеше) 1939 нчы елны, Себер шартларында, долгунец җитеннең һәр гектарыннан (барлыгы 11,5 гектар) 9 центнер сүс уңышы алган. Звено баштан ахрына кадәр бөтен агрономия чаралары комплексын һәм бөтен эшне үз көчләре белән башкарган. Монда 20 сантиметр тирәнлектә туңга сөрелгән җиргә, „Д—83“ сортлы селекцион орлык чәчелгән. Яз көне туфракны ике тапкыр культивацияләгәннәр. 5 гектар җитенне 27 нче апрельдә, ә 6,5 гектарны 7 нче майда чәчкәннәр (һәрбер гектарга 120 килограмм орлык чәчелгән). Культивацияләгән вакытта һәр гектарга 5 центнер көл, 2 центнер кош тизәге һәм тукландыру төсендә 60 килограмм кали тозы кертелгән. Бөтен мәйдан чүп үләннәреннән җентекләп чистартылган һәм 3 гектар җирдә ике тапкыр утау үткәрелгән. Нәтиҗәдә звено югары уңыш алуга ирешкән. Мәсәлән, чәчүлекнең һәрбер гектарыннан 3,5 центнер орлык, иртә чәчелгән 5 гектардан 12 шәр центнер һәм 6,5 гектардан 7 шәр центнер сүс алынган. Шул ук колхозда Старченкова һәм Трунова иптәшләрнең бригадалары бөртекле культуралар буенча һәр гектардан 28 центнер уңыш алганнар.

Бездә дә бу өлкәдә яхшы эш үрнәкләре күрсәтүче районнар бар. Мәсәлән, Ютазы районында 14 ефремовчы звено эшли. Алар үзләренә беркетелгән участкыларда кар тоту үткәреп, кар катлавын бер метрга кадәр җиткерделәр. Хәзер алар рекорд участкыларына чәчү өчен орлыкларны кул белән сайлап алу эшен алып баралар.

Теләче һәм Аксубай районнары да звенолар төзү өлкәсендә зур эш башкардылар.

Ефремовчы звеноларның төп оештыру принциплары даими звеноларныкы кебек үк. Ләкин бу ике форманы бергә буташтырырга ярамый. Даими звено—ул, кырчылык бригадасында хезмәтне оештыруның яңа формасы. Ефремовчы звено исә—барыннан да элек, стахановчы звено, ул хезмәтнең стахановчы методларын үзләштерүче һәм яңа агротехниканы киң кулланып ныклы, югары уңыш алучы звено.

Һәрбер даими звено ефремовчы звено була ала. 1939 нчы елны Алтай краенда күп кенә колхозларда ефремовчы звенолардан ефремовчы бригадаларга һәм хәтта ефремовчы колхозларга күчтеләр.

Ефремовчылык хәрәкәтенә участкылардан рекордлы уңыш алу өчен тәҗрибә үткәрү эше дип кенә карарга ярамый. Стахановчылык, ефремовчылык хәрәкәтенең көче—аның массовый төстә булуыннан гыйбарәт. Хәзер, Татарстанда колхозларның производство планнарын, бригадалар һәм звенолар өчен эш планнары төзү барганда, даими һәм ефремовчы звеноларны да агротехниканың барлык төп чараларын эченә алган дөрес һәм нык уйлап төзелгән план белән тәэмин итәргә кирәк.

Звено башлыкларын һәм членнарын сайлап алу—зур әһәмиятле эш. Алар эшнең барлык өлкәләрендә дә бөтен агрокомплексны үткәргәндә хезмәтнең җитештерүчәнлек һәм дисциплиналылык үрнәкләрен күрсәтергә сәләтле булырга—яңа эшнең энтузиастлары булырга тиеш. Ефремовчылык хәрәкәтен җәелдерүдә партия һәм комсомол оешмалары зур урын тоталар. МТС ларның, совхозларның, район җир бүлекләренең һәм фәнни учреждениеләрнең агрономия көчләре бу хәрәкәткә ярдәм күрсәтергә тиешләр. Яз килеп җитте. Язгы чәчүне лаеклы рәвештә каршылыйк һәм аны отличнога үткәрик.

Н. Шибдин.

ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы.

Чит илләрдә

Франциянең депутатлар палатасының 22 нче мартта булган утырышы турында кайбер тулы хәбәрләр

БРЮССЕЛЬ, 23 март. (ТАСС). Журналистлар даирәләрендә Франция депутатлар палатасының 22 нче мартта булган утырышы турында кайбер тулы хәбәрләрне иглан итәләр. Палата утырышында Даладье булмаган. Статс-секретарьларның берсе—Граммэзон утырыш алдыннан отставкага чыккан, чөнки ул член булып торган „республикачылар федерациясе" группасы кабинетка ышаныч белдерүдән баш тарткан. Хөкүмәткә ышаныч белдерүне тавышка куйганда „республикачылар федерациясе" группасы членнары, 10 радикал-социалист, „Альянс демократик"ның 24 члены, „бәйсез республикачылар" группасының 18 члены (бу группаның вәкилләре хөкүмәткә керәләр), „сул демократик" группаның һәм „бәйсез радикаллар"ның 28 члены һәм башкалар каршы тавыш биргәннәр. Хөкүмәткә каршы тавыш бирүчеләр арасында бәйсез радикаллар Мистлер һәм Леон Мейер, ә тавыш бирмичә калучылар арасында Боннэ, Боссутро, шулай ук Фроссар группасы членнарыннан Лафай, Деа һәм башкалар булганнар. Парламенттагы уңнарның вәкилләре үзләренең речьләрендә хәзерге хәлнең „кискен политика" таләп итүен, ә шул ук вакытта социалистларның үзләрен бу яктан караганда „начар кяилар белән" күрсәткәнлекләрен сызлау итеп сәф хәрби кабинет төзүне һәм кабинет составыннан социалистларны чыгаруны таләп иткәннәр. Күп кенә уңнар үзләренең речьләрендә советка каршы кискен чыгышлар ясаганнар. Уң Фернан-Ларэн үзенең речендә, 1932 нче елны Амстердамда сугышка каршы конгресста катнашкан блокада министре Жорж Моннэның ул вакытта „милли оборонага каршы" чыкканлыгын белдергән. Социалист Моннэ мона җавап итеп, „8 ел элек күп нәрсә үзгәргәнлекне һәм 1939 нчы елның сентябрендә үзенең теләп армиягә кергәнлеген" белдергән. Социалистларның башлыгы Леон Блюм, социалистларның „хәзерге шартларны аңлаганлыгын" һәм „хөкүмәткә аларның намус белән эшләячәкләрен", хөкүмәтнең гаять тын һәм тулысынча ышанычка лаеклыгын белдергән. Блюм „моннан 3 ел элек без Шотан хөкүмәтенә кердек һәм аның турылыклы һәм лойяль сотрудниклары булдык" дип белдергән. Блюм хөкүмәтнең коммунистларга каршы тагын да кискенрәк көрәш алып баруын таләп иткән.

Англия хөкүмәтендә үзгәрешләр булу ихтималы турында Англия матбугаты

ЛОНДОН, 24 март. (ТАСС). Политик даирәләр Англия хөкүмәте составында үзгәрешләр булу мөмкинлеген нык тикшерәләр. Парламентның пасха каникулларына тарату алдыннан парламент кулуарларында хөкүмәт составын үзгәртү генә түгел, бәлки кечрәк, ләкин тагын да нәтиҗәлерәк хәрби кабинет төзү кирәклеге күрсәтелгән иде. „Обсервер" газетасының язуына караганда, авиация министры Кингсли Вуд, сәүдә пароходчылыгы министры Гильмур, азык белән тәэмин итү министре Моррисон, тау промышленносте департаменты җитәкчесе Ллойд һәм транспорт министре Уоллес нык тәнкыйтьләнгәннәр. Кайбер даирәләр Чемберленның лейбористлар һәм либераллар партияләренә хәрби кабинетта катнашырга тагын тәкъдим итүе ихтималы турында сөйләшәләр. Күпчелек якшәмбе газеталарының политик күзәтүчеләре пасха каникулы вакытында яки каникулдан соң ук хөкүмәт составын үзгәртү турында Чемберлен карар кабул итәр дип көтәләр.

ГЕРМАНИЯ—РУМЫНИЯ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

БЕРЛИН, 24 март. (ТАСС). Шушы көннәрдә „Гавас", Рейтер агентлыгы, шулай ук Англия һәм Франция газеталары, Германиянең Румыниягә ультиматум характерында нота биреп, Румыниядән нефть кертүне арттыруны, экспорт тарифларын киметүне һәм Румыния леясына маркалың яңа курсын билгеләүне таләп иткәнлеге турында хәбәрләр таратканнар иде. Кичә Румыния телеграф агентлыгы Радор бу хәбәрләрне кискен төстә юкка чыгарды. Германия информация бюросы да бу хәбәрләрне юкка чыгарды.

Бүген Германия информация бюросы болай дип хәбәр итә: „Инде мәгълүм булганча, Рейтер агентлыгы гуя Германиянең Румыниягә ультиматум биргәнлеге турында хәбәр тараткан. Румыниянең тиешле органнары бу хәбәргә ялган дип бәя бирделәр. Пропаганда министре Джиуреску 23 нче мартта чит ил матбугатының Бухарестагы берничә вәкилен чакырып, аларга шунда ук үзләренең юкка чыгарылган хәбәрләрне таратмаска таләп иткән, шулай итеп мәгълүм Румыния властьларының мондый хәбәрләргә карата тиешле чаралар күрү турында белдергән. Румыниянең пропаганда министре, Гавас агентлыгы тарафыннан таратылганнарны белгәч, ике агентлыкның да вәкилләрен үз янына чакырып, аларга я бу хәбәрләрне кире алу, я Румыниядән китәргә тиеш булулары турында хәбәр иткән."

ПАРИЖ, 24 март. (ТАСС). Гавас агентлыгы хәбәр итүенә караганда, Рейтер агентлыгының Бухарестагы хәбәрчесе Ловеллны Румыния властьлары Румыниядән җибәргәннәр. Ул 24 сәгать эчендә Румыниядән китәргә тиеш.

Курчак хөкүмәт вәкилләренең Нанкиндагы конференциясе турында Кытай матбугаты

ЧУНЦИН, 25 март. (ТАСС). Мәгълүм ки, японнарның таләп итүе буенча, Нанкинда курчак хөкүмәт вәкилләренең Ван Цзин-вей белән ванцзинвейчыларның конференциясе булган иде. Конференциянең составы Ван Цзин-вейнең үз тирәсенә хыянәтчеләрдән башка бер кемне дә туплый алмаганлыгын күрсәтә.

Япон генераллары Нисиоңың күрсәтүе буенча, конференция 30 нчы мартта „үзәк хөкүмәт" төзергә карар биргән. Билгеләнгән план буенча, Нанкиндагы һәм Бэйпиндагы курчак хөкүмәтләр 24 нче мартта берләштерелгән утырыш үткәргәннәр, 29 нчы мартта—„үз-үзләрен тарату" турында иглан итәргә тиешләр иде.

Хәтта үз юлдашлары арасында да ризасызлык тууданкуркып, Нанкиндагы конференция башта „хөкүмәт" төзүне һәм чит ил державаларының тануына ирешүне кирәк дип табып, хәзергә японнар белән килешүнең шартларын иглан итмәгән. Конференция Ван Цзин-вейне Кытай белән Япония арасындагы мөнәсәбәтләрнең төп шартларына „хөкүмәт" исеменнән кул куярга вәкил иткән.

Конференциянең политик программасы түбәндәге 3 пунктка кайтып кала: „1. Япония белән яхшы күршеләрчә мөнәсәбәт. 2. Коммунизмга каршы бергәләп саклану. 3. Экономик яктан бергәләп эшләү".

Рейтер агентлыгы Ван Цзин-вей курчак хөкүмәт составына керә торган кешеләрне исемләп иглан итте инде. Бу хөкүмәт 5 юаньнан (палатадан) һәм 14 министрлыктан тора. Ләкин Кытай матбугаты курчак хөкүмәт вәкилләре арасындагы ызгышларның дәвам итеп килүен күрсәтә.

Англиянең һәм Франциянең АКШ тан сугыш кирәк-яраклары сатып алулары

НЬЮ-ЙОРК, 24 март. (ТАСС). „Нью-Йорк таймс" газетасы хәбәр итүенә караганда, Вашингтонның мәгълүм бер даирәләре, рәсми кешеләр Америка властьларының Англиягә һәм Франциягә АКШ та өр яңа типтагы 2 мең чамасы самолет сатып алу хокукы биргәннәр. Бу самолетларга инде Америка армиясе заказ биргән булган.

Шул уңай белән хәбәрче конгрессның сугыш министрлыгына 1941 нче елның июленә кадәр 5.500 самолет сатып алырга рөхсәт биргәнлеген хәбәр итә. Бу самолетларның 2 меңләбе резерв өчен билгеләнгән.

ТАЗАЛАР ҺӘМ ҖИТЕЗЛӘР ЯРЫШЫ

Бөтен ел әйләнәсендә, төрле вакытларда, спортның төрле төрләре буенча үткәреләторган ярышлар бездә физкультура-спорт хәрәкәте үсешенең иң матур күрсәткече булып торалар. Аларда без таза, җитез һәм чыныккан кешеләрнең оста хәрәкәтләрен, гаять өлгер булуларын күрәбез.

Балаларның кичә башланган гимнастика ярышлары әнә шуңа ачык мисаль була ала. Катнашучыларның матур парадыннан соң, ирекле хәрәкәт, турник, брусья һәм башка снарядларда катлаулы хәрәкәтләр ясау буенча алдынгы урыннарны алу өчен үсмер ир балалар һәм кыз балалар командалары арасында көрәш башланды. Узган ел Свердловскийда булган ярышларда беренчелек өчен көрәш нигездә Архангельский, Свердловский һәм Казан командалары арасында барган иде. Ярышларның беренче көне нәтиҗәсе быел, югарыдагы командалар өстенә, Куйбышев, Ижевский һәм Киров командаларының да яхшы хәзерләнгәнлеген күрсәтте. Куйбышевның үсмер кыз балалар командасы бик яхшы чыгыш ясады һәм казанлылардан бик аз гына артка калды. Сутягина, Гыймазеттинова, Казанцева һәм Ефимова иптәшләрдән торган казанлылар командасы, көннең иң яхшы күрсәткечен биреп, быел да беренче урын өчен нык көрәшәчәген күрсәтте. Архангельский группасы хәзергә 3 нче, Свердловский—4 нче һәм Киров—5 нче урында баралар. Аннан соңгы урыннарда Ижевский, Уфа, Чиләбе, Чебоксар һәм Молотов шәһәрләренең командалары бара. Горький һәм Магнитогорскпй шәһәрләреннән командалар килмәде.

Үсмер ир балалар командалары ярышында да беренче көнне Казан (Крейнин, Матков, Янин һәм Зайцев) командасы өстен чыкты. Куйбышев—2 нче, Ижевский—3 нче һәм Свердловский—4 нче, Киров—5 нче урында баралар. Архангельский командасы беренче көнне уңышсыз чыгыш ясады һәм хәзергә әле 6 нчы урын белән канәгатьләнергә мәҗбүр булды. Аннан соң Чиләбе, Уфа, Чебоксар һәм Молотов командалары бара.

Казанлылардан Крейнин һәм Сутягина, куйбышевлылардан Кулакова һәм Карыгин иптәшләр иң яхшы күрсәткечләрне биреп, беренче көн ярышында иң алдынгы урыннарны алдылар.

Ярышлар бүген иртә белән сәгать 10 нан Менжинский исемендәге клубта дәвам итә.

Хәй.

М. В. ЛОМОНОСОВНЫҢ ҮЛҮЕНӘ 175 ЕЛ ТУЛУГА КАРАТА

Татарстан АССР ның фәнни көтепханәсендәге кулъязмалар һәм сирәк очрый торган китаплар бүлегендә русның беренче галиме М. В. Ломоносов тарафыннан язылган китаплар саклана. Алар арасында „Российская грамматика", „Похвальное слово Петру I", „Первые основания металлургии или рудных дел" дигән әсәрләрнең һәм Ломоносовның башка хезмәтләренең беренче басмалары бар.

Бу китаплар барсы да М. В. Ломоносов үлүенә 175 ел тулуга карата фәнни көтепханә тарафыннан оештырыла торган күргәзмәдә күрсәтеләчәкләр.

Казанның үзәк көтепханәсендә дә юбилейгә карата китаплар күргәзмәсе хәзерләнә. Анда Ломоносов хезмәтләре, аның тормышы һәм эше турындагы әдәбият күрсәтеләчәк.

Балаларның Татарстан республикасы күләмендә үткәреләчәк художество үзешчәнлек олимпиадасына карата РӘСЕМДӘ: Пионерлар йортында яшь домбрачылар иптәш Л. П. Федоров җитәкчелегендә занятие вактында.

И. Галиев фотосы.

Каникул көннәрендә

Укучы балаларның язгы каникуллары башланды. Пионерлар һәм Мәктәп Балалары йорты каникул вактында балалар өчен күп кенә кызыклы чаралар үткәрә. Казан шәһәре мәктәпләрендә укучылардан 30 га якын иң оста шахматчы һәм шашкачы беренчелек өчен үзара ярышачаклар. Шашка-шахмат турниры 29 нчы мартка кадәр дәвам итәчәк.

Укучы балаларның район күләмендә үткәрелә торган үзешчәнлек сәнгате көчләренә смотрлар каникул вактына туры китерелде. 24 нче мартта Молотов һәм Сталин районнарына кергән мәктәпләрнең художество үзешчәнлеге көчләренә смотрлар булды. 25, 5, 20, 19, 2 һәм 51 нче номерлы мәктәпләрнең чыгышлары тамашачыларда аеруча яхшы тәэсир калдырды. Бу мәктәпләрнең җыр һәм бию ансамбльләре, шумовой оркестрлары, җырчылары һәм декламаторлары зур уңыш белән чыктылар. Шулай ук Бауман районы мәктәпләренең үзешчәнлек сәнгате көчләренә дә смотр үткәреләчәк. Балалар өчен ял һәм күңел ачу кичәләре оештырыла.

30 нчы мартта СССР, РСФСР һәм ТАССР Верховный Советлары депутатлары белән пионерларның һәм уку отличникларының очрашу кичәсе булачак. Балалар кичәгә үзләренең иң яхшы номерларыннан концерт хәзерлиләр.

АВЫЛЛАРНЫ ТЕЛЕФОНЛАШТЫРУ

Шушы елның 1 нче январена кадәр Татарстан АССР да телефонлаштырылган авыл советларының саны 1.422 гә җитте. Шулай ук 98 МТС һәм 59 совхоз телефонлаштырылды. Быел яңадан 16 авыл советына һәм 1 МТС ка телефон линияләре сузыла.

Телефон кертелгән авыл советларының башкарма комитетлары телефон аркылы район үзәкләре белән турыдан-туры элемтә тоталар. Аларның 80 проценты Казан белән дә сөйләшә ала. Татарстан авылларындагы телефон линияләренең озынлыгы 12 мең километрга, аларга куелган проводларның озынлыгы 25 мең километрга сузыла. Бу линияләрдә быел зур ремонт эшләре үткәрелә. Аларга 10 меңнән артык багана утыртылачак, 561 километрга икенче проводлар куелачак һәм 62 километр озынлыкта яңа линияләр ясалачак.

Телефон аппаратларының эшләрен көчәйтү өчен Теләчедәге трансляция пунктына реконструкция ясала. Арча, Кызыл Юл, Чепья һәм Балтач районнарына хезмәт күрсәтүне яхшырту өчен Арча белән Казан арасында яңа линия корыла.

Республика олимпиадасына хәзерлек

Апрельнең беренче декадасында Зеленодольски шәһәрендә художество үзешчәнлеге түгәрәкләренең шәһәр олимпиадасы башлана.

Клубларда һәм предприятиеләрдә бу олимпиадага хәзерлек бара. Үзешчәнлек коллективлары һәм аерым башкаручылар республика күләмендә үткәрелә торган олимпиадага катнашу хокукы алу өчен көрәшәләр.

3 нче фанера заводы клубының рус драмколлективы (җитәкчесе иптәш Лаврин) А. Островскийның „Гаепсез гаепләләр"ен, татар драмколлективы (җитәкчесе иптәш З. Измайлова), К. Шамилның „Җәмилә"сен хәзерлиләр. Тынлы оркестр (җитәкчесе иптәш Отруков) Чайковскийның „Пиковая дама" операсыннан өзекләр һәм башка номерлар хәзерли.

М. Горький исемендәге завод клубында да олимпиадага хәзерлек эше киң күләмдә җәелдерелде. Клуб янындагы рус драмколлективы (җитәкчесе иптәш Бобров) А. Островскийның „Ярлылык—кимчелек түгел" („Бедность—непорок") дигән әсәрен, Г. Түтүрүш җитәкчелегендәге татар драмколлективы Р. Ишморатның „Ил өчен" дигән пьесасын куячаклар. Тынлы оркестр Чайковскийның „Евгений Онегин" операсыннан увертюра һәм башка номерлар хәзерли.

И. Фәйзуллин.

КОЛХОЗЛАРДА СЕЗОНЛЫ ЯСЛЕЛӘР

Язгы чәчү һәм урып-җыю вактында колхозларда балалар өчен сезонлы ясләләр ачуга хәзерлек бара. Быелгы план буенча Татарстан колхозларында 130 мең бала өчен 4.039 ясле оештыру күздә тотыла. Узган ел колхозларда оештырылган сезонлы ясләләрдә 100 меңгә якын бала тәрбияләнгән иде.

Ясләләргә мөдирләр хәзерләү өчен районнарда курслар оештырыла. Курсларда 1.800 кеше хәзерләнәчәк. Курсларны оештыруга 65.500 сум акча җибәрелде. Узган ел колхоз ясләләре өчен мөдирләр хәзерләү курсларында 1.200 кеше хәзерләнгән иде.

УЛӘН ЧӘЧҮ

Быел Татарстан колхозларында үлән чәчү мәйданы шактый киңәйтелә. Яхшы сорт чәчүлек орлык җитештерү өчен Арча районы колхозларында яңадан 600 гектар, Балтач, Кукмара һәм Мамадыш районнарында 1.500 гектар мәйданга клевер чәчелә. Буа, Куйбышев, Тархан, Октябрь һәм Тымытык районнарындагы колхозларда чәчүлек орлык җитештерү өчен 3.000 гектар мәйданга люцерна чәчеләчәк.

„Трикотаж" артелендә

Яңа алфавитны өйрәнү буенча „Трикотаж" артелендә январь һәм февраль айларында курслар оештырылган иде. Укучы иптәшләрнең тырышып йөрүләре һәм укытучыларның яхшы укытулары нәтиҗәсендә, 35 кеше „яхшы" һәм „отлично" билгеләре белән курсны тәмамлап чыктылар.

Оештыру эшендә һәм укуда Зарипова, Сәйфуллина, Җиһаншина, Кушаева, Дәминова иптәшләр аеруча активлык күрсәттеләр.

И. Кәрим.

Балаларда була торган эч китү авыруларына каршы көрәш

Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты балаларның эч китү авыруларына каршы көрәш буенча күп кенә чаралар үткәрә. Авыру балаларны дәвалау өчен район больницаларында 400 койка, Казан больницаларында 300 койка беркетелде.

Балаларның эч китү авыруларына каршы көрәш буенча инструкторлар һәм сестралар хәзерләү өчен Казанда врачларның белемен күтәрү институты янында курслар ачыла. Курсларда 64 инструктор һәм 120 сестра хәзерләнәчәк. Район больницаларындагы фельдшерларның белемен күтәрү өчен дә курслар оештырыла. Курсларда 60 фельдшер укыячак. Алар балаларның эч китү авыруларын дәвалау өстендә эшләячәкләр. Балалар консультацияләре яшь балаларның сәламәтлекләрен системалы рәвештә тикшереп торуны оештыралар. Күкрәк сөте белән тәрбияләнә торган балалары булган хатыннарның өйләренә махсус сестралар барып, балаларның иичек тәрбияләнүләрен күзәтеп торачаклар һәм авыру балаларга үз вактында медицина ярдәме бирәчәкләр

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Үтерү. Кукмара районы Камышлы авылы колхозының ат караучысы Хуҗа Җамалиев төнге сменада торган вакытта, үзенең авылдашы Рамазан Сираев дигән кешенең ашыга-ашыга каяндыр кайтканлыгын күргән. Сираев шул төнне үк авылдан качып киткән. Икенче көнне Җамалиев өенә кайткач, үзенең хатыны Мәмдуха Җамалиеваны үтерелгән хәлдә тапкан. Җинаятьче аны үтергәннән соң 60[illegible] сум акча белән төрле киемнәрне урлап алып киткән булган. Казаннан һәм Кукмарадан милиция работниклары барып тикшерү ясагач, Сираевның артыннан куып барганнар һәм Синер авылында аны кулга алганнар. Сираев Җамалиеваны үтергәнлеген икрар итәргә мәҗбүр булган. Урланган әйберләр аның янында табылган. Сираев суд җаваплылыгына тартыла.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.

Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Район сәламәтлек саклау бүлекләре, колхоз правлениеләре һәм МТС лар игтибарына

РСФСР Наркомздравы Аптекалар Баш Идарәсенең Татарстан бүлеге алдагы чәчү кампаниясенә карата

КОЛХОЗ АПТЕЧКАЛАРЫ

ШУЛАЙ УК

ЯСЛЕ АПТЕЧКАЛАРЫ

хәзерләде һәм барлык район аптекаларына җибәрде.

Район аптекаларыннан колхоз һәм ясле аптечкалары бирелмәү хәлләре булса, түбәндәге адрес буенча, Аптекалар Баш Идарәсенең Татарстан бүлегенә мөрәҗәгать итәргә. Казан, Профсоюз урамы, 26. 522—2—1

Казанда (Кече-Галактионов урамы, 24. Телефон 3—76)

А. М. ГОРЬКИЙ МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ

Музей эш көннәрендә көндез 12 сәгатьтән кич 6 га һәм гомуми ял көннәрендә көндез 10 сәгатьтән 4 кә кадәр ачык. Атнаның 1 нче көннәрендә музей эшләми. 510—2—2

Горпромторгның әйберләр сатып алу пунктларында

дәүләт учреждениеләреннән, предприятиеләрдән, кооператив һәм җәмагать оешмаларыннан хәзер акчага

ТӨРЛЕ ӘЙБЕРЛӘР САТЫП АЛЫНА

ӘЙБЕРЛӘР ТҮБӘНДӘГЕ ПУНКТЛАРДА АЛЫНА:

Куйбышев урамы, 7—паласлар, картиналар, язу һәм исәпләү машиналары, мебель, кесә һәм стена сәгатьләре.

Бауман урамы 10 нчы йортта һәм Чернышевский урамында Пассажда—паласлар, картиналар язу һәм исәпләү машиналары, кесә, стена сәгатьләре һәм башка әйберләр.

Ягодный бистәсендә—паласлар, картиналар, кесә һәм стена сәгатьләре һәм башка әйберләр. 479—3—1

СССР НАРКОМЗДРАВЫНЫҢ

КАЗАН ПСИХИАТРИЯ БОЛЬНИЦАСЫ

(Ершов кыры, 5, телефон 32)

медика санитария учреждениеләренә һәм Казан шәһәре халкына белдерә:

Стационар рәвештә дәвалау өчен авырулар шушы ел 1 нче апрельдән (больницага ашыгыч рәвештә салынырга тиешле авырулардан башка) район психиатрлары тарафыннан бирелгән путевкалар буенча гына алыналар.

Амбулаториядә дәвалау өчен авыруларны кабул итү һәм авырулар янына район психиатрларын чакыртуны язу түбәндәге урыннарда үткәрелә: Бауман һәм Ленин районнарындагы авырулар өчен—1 нче номерлы үзәк поликлиникада (Красный урамда, кабул итү көндез 3 сәгатьтән), Молотов һәм Киров районнарындагы авырулар өчен—2 нче номерлы поликлиникада (Комлев урамында, кабул итү көндез 3 сәгатьтән), Сталин районындагы авырулар өчен—Вахитов поликлиникасында (Тукай урамы, кабул итү көндез 4 сәгатьтән). 534—3—1

ТАТАРСТАН АССР ның ҮЗӘК МУЗЕЕ

(Чернышевский урамы, 2)

Гражданнар сугышы, хәрби коммунизм, хуҗалыкны аякка бастыру чоры белән бәйләнешле һәм ул чор өчен характерлы булган әйберләр, документлар, фото-рәсемнәр (кораллар, киемнәр, азык документлары, зажигалкалар, гражданнар сугышында катнашучыларның фото-рәсемнәре һәм башка әйберләр) ҖЫЯ ҺӘМ САТЫП АЛА 455—3—3

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Татар Дәүләт Академия театры бинасында

Иртәгә, 28 нче мартта

ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ

Талоннар белән кертелми.

Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген һәм һәр көн

ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ

(Һәр көн 3 пар көрәшә)

һәм зур программа буенча

ЦИРК УЕНЫ

Уен кич 8 дә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

2 нче апрель, кич 6 сәгатьтә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетының 4 нче аудиториясендә университетның физика-математика факультеты гыйльми советының ачык утырышы чакырыла һәм физика-математика фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен иптәш Ш. Г. Хәкимов тарафыннан халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ

яклау үткәрелә

Тема: „Бәйләнешле ноляномлы өченче тәртиптәге линейный дифференциаль тигезләмәләр турында".

Рәсми оппонентлар: профессор Б. М. Гагаев һәм профессор К. П. Персидский.

Утырышка Казан шәһәре ВУЗ ларының фәнни работниклары чакырылалар. 541—1

КИРӘК:

„Гужтранс-Заречье" артеленә даими эшкә СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, ХИСАПЧЫ һәм КАРТОТЕКАЧЫ. Ягодный бистәсе, Краснококшай урамы, 85. Телефон 26—33. 491—2—1

Фото-Желатин заводы төзелешенә, монтаж һәм эксплоатация буенча эшләү өчен 6—7 нче РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР. Тору урны бирелә. Казан, Восстание бистәсе, Фото-Желатин заводының кадрлар бүлеге. 474—5—3

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

27 һәм 28 нче мартта

ЛЕНИН

29 нчы мартта күңелле комедия ПРЕМЬЕРА

„КУРКЫНЫЧЛЫ" СУД

Талоннар белән кертелми.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.

Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

„ЭЛЕКТРО" кинотеатры

БАЛАЛАР!

31 нче мартка кадәр һәр көн сезнең өчен махсус рәвештә иртәнге сеанслар үткәрелә.

БИЛЕТ БӘЯСЕ 50 ТИЕН.

Кинога коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.

Дирекция. 2—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ПРЕМЬЕРА ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 2, 4, 6, 8, 10 да.	ҺАВА ПОЧТАСЫ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ДИПКУРЬЕР СУМКАСЫ
„ПИОНЕР" 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5-, 6-30, 8-20, 10 да.	ШӘХСИ ЭШ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	Гроза
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	КЕЧКЕНӘ АНА

Уполн. Главлита ТАССР № А — 1311 Типография имени Александрова. Дом печати 1940 год. ЗАКАЗ № 1163.